ЧӘРШӘМБЕ
24 АПРЕЛЬ
1940 ел
№ 95 (5895)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ: Казан, Матбугат йорты. ТЕЛЕФОННАР: экономик һәм культура бүлекләре 18—22, авыл хуҗалыгы 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, информация һәм совет төзелеше бүлекләре 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игъланнар бүлеге 2—19.

СССР ның көнчыгыш районнары: Алтай һәм Красноярск крайлары, Новосибирск, Омск, Чиләбе өлкәләре; Акмолинск, Павлодар, Төньяк Казагстан, Кустанай, Семипалатинск һәм Көнчыгыш Казагстан өлкәләре колхозларында һәм совхозларында бөртекле ашлык хуҗалыгын тагын да күтәрү турында

ССР СОЮЗЫ ХАЛЫК КОМИССАРЛАРЫ СОВЕТЫ ҺӘМ ВКП(б) ҮЗӘК КОМИТЕТЫ КАРАРЫ

СССР Совнаркомы һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты, колхоз строеның җиңүе һәм югары дәрәҗәдә механикалаштырылган игенчелек булдырылу нигезендә СССР ның көнчыгыш районнарының авыл хуҗалыгын шактый күтәрүгә ирешкәнлекләрен күрсәтеп үтәләр. Сугышка кадәрге вакыт белән чагыштырганда, чәчү мәйданнары ике тапкырдан күбрәк артты, икенче бишьеллык эчендә генә дә 7 миллион гектарга якын яңа җирләр үзләштерелде, игеннәрнең уңышы күтәрелде, ә бөртекле культураларның валовой уңышы Совет власте еллары эчендә дүрт тапкыр чамасы артты һәм 1938 нче елны бер ярым миллиард потка җитте.

Шул ук вакытта, СССР Совнаркомы һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты көнчыгыш районнарның авыл хуҗалыгында җидди кимчелекләр барлыкны күрсәтәләр: туңга сөрү планнары елдан-ел үтәлми киләләр; пар җирләрен эшкәртү түбән дәрәҗәдә; туңга сөрүдә дә, шулай ук пар җирләрен сөрүдә дә сай сөрү әле һаман да киң кулланыла; бөртекле культуралар чәчелгән җирләргә тоташтан берничә еллар буена бөртекле культуралар чәчелә, бу хәл басуларның чүпләнүенә китерде; эшнең канәгатьләнерлек оештырылмавы һәм яз көне сөрүнең күләме зур булу аркасында, чәчү сроклары озакка сузыла, ә урып-җыю срокларының озакка сузылуы нәтиҗәсендә колхозларда һәм совхозларда һәр елны күп кенә уңыш югала.

Көнчыгыш районнарның авыл хуҗалыгындагы бу зур кимчелекләрнең бөтенесе өчен СССР Наркомземы, СССР Наркомсовхозы, шулай ук крайлардагы һәм өлкәләрдәге җитәкче совет һәм партия органнары җаваплы.

Хәлбуки, Союзыбызның көнчыгыш районнарында югары дәрәҗәдә механикалаштырылган авыл хуҗалыгы, яхшы туфрак һәм һава шартлары һәм әлегә кадәр эшләнми ята торган уңдырышлы гаять күп җирләр булганлыктан анда бөртекле культуралар, бигрәк тә сабан бодае уңышын тагын да күтәрү һәм аларның валовой уңышын арттыру өчен гаять зур мөмкинлекләр бар.

СССР ның көнчыгыш районнарының өлкә һәм крайларындагы җитәкче партия һәм совет оешмалары алдына, колхозлар һәм совхозлар алдына иген уңышын гектарыннан уртача 15—16 центнерга кадәр күтәрү бурычын куеп, СССР Совнаркомы һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты карар бирәләр:

I.

ИГЕН УҢЫШЫН КҮТӘРҮ ҺӘМ ЯҢА ҖИРЛӘРНЕ ҮЗЛӘШТЕРҮ ЧАРАЛАРЫ ТУРЫНДА

СССР Наркомземын, СССР Наркомсовхозын, ВКП(б) ның өлкә һәм край комитетларын, өлкә, край башкарма комитетларын, Казагстан ССР компартиясе Үзәк Комитеты һәм Совнаркомын мәҗбүр итәргә:

1. Союзның көнчыгыш районнарындагы крайларындагы һәм өлкәләрендәге колхозларда һәм совхозларда сөрелми ята торган кысыр һәм чирәм җирләр исәбенә сөрү җирләре мәйданын 1942 нче ел азагына 4 миллион 345 мең гектарга яңа җирләр арттырырга. Шул исәптән 1940 нчы елны 1 миллион 422 мең гектарга, 1941 нче елны 1 миллион 458 мең гектарга һәм 1942 нче елны 1 миллион 465 мең гектарга арттырырга, бу саннарны крайлар һәм өлкәләр буенча түбәндәгечә бүләргә (мең гектарлар белән):

	1940 ел		1941 ел		1942 ел	
	Колхозларда	Совхозларда	Колхозларда	Совхозларда	Колхозларда	Совхозларда
Чиләбе өлкәсе	115	69	115	60	135	50
Омск өлкәсе	200	59	175	35	145	35
Новосибирск өлкәсе	210	50	200	40	200	40
Алтай крае	290	54	278	30	300	30
Красноярск крае	100	38	125	40	80	40
Казагстан ССР ның төньяк-көнчыгыш өлкәләре	127	110	260	100	300	110

Сөрү җирләрен киңәйтүне беренче чиратта аларны үзләштерү өчен артык күп көч тотуны таләп итми торган районнарда һәм җирләрдә үткәрергә. Авыл хуҗалыгы эшләренең бөтен төре өчен машина-трактор паркыннан һәм эш көчләреннән тулысынча һәм тигез файдалану өчен кысыр һәм чирәм җирләрне сөрүне бөтен җәй буена алып барырга.

2. Көнчыгыш районнарда бөртекле культуралар чәчү мәйданнарын 1941 нче елны 17 миллион 865 мең гектарга, 1942 нче елны 18 миллион 830 мең гектарга җиткерергә, бу саннарны крайлар һәм өлкәләр буенча түбәндәгечә бүләргә:

	1941 ел	1942 ел
Чиләбе өлкәсе	3.110 мең га	3.240 мең га
Омск өлкәсе	2.690	2.800
Новосибирск өлкәсе	2.940	3.140
Алтай крае	3.490	3.650
Красноярск крае	1.800	1.900
Казагстан ССР ның төньяк-көнчыгыш өлкәләре	3.835	4.100

3. Крайлар һәм өлкәләр буенча 1943 нче елны бөртекле ашлыкның валовой уңышын түбәндәге күләмнәргә җиткерергә (миллион потлар белән):

Чиләбе өлкәсе — 325
Омск өлкәсе — 280
Новосибирск өлкәсе — 320
Алтай крае — 370
Красноярск крае — 190
Казагстан ССР ның төньяк-көнчыгыш өлкәләре — 390

4. Барлык колхозларда һәм совхозларда бер-ике чиста пар басуы, ике күп еллык үләннәр басуы һәм 4 тән 6 га кадәр бөртекле һәм техник культуралар басуы булган дөрес чәчү әйләнешләре кертергә. Далалы районнардагы аерым колхозларда һәм терлекчелек совхозларында өч басудан ким булмаган күп еллык үләннәр басулы чәчү әйләнешләре кертергә юл куярга. Чәчү әйләнешләренә күп еллык үләннәр басуының бер өлешен, яки бөтен бер басуны да алу мөмкин. Далалы зоналарда һәм күп еллык үләннәр һәм чиста пар белән күбесенчә 9—10 басулы, урманлы-далалы зонада 8—9—10 басулы һәм тайга янындагы зонада 7—8—9 басулы чәчү әйләнешләре кертергә. Колхозларда һәм совхозларда аларның хуҗалыклары таләпләренә җавап бирә торган җирле басулы чәчү әйләнешләрен сайлап калырга.

5. „СССР ның көнчыгыш районнарында уҗым чәчүләрен киңәйтү һәм аларның уңышын күтәрү чаралары турында" СССР Совнаркомының һәм ВКП(б) Үзәк Комитетының 1939 нчы ел, 4 нче январь карарына өстәмә итеп, көнчыгыш районнарда колхозларга һәм совхозларга чәчү әйләнешләрен керткән вакытта дөрес чәчү әйләнешләрендә уҗым (арыш һәм бодай) чәчүләре мәйданын бер басуга кадәр һәм уҗымнарның киңәйтелүе булган колхозларда ике басуга кадәр җиткерергә, уҗым чәчүләрен киңәйтүне кыска вакытта тормышка ашырырга тәкъдим итәргә.

6. 1940 нчы елны крайлар һәм өлкәләр буенча колхозларның һәм совхозларның түбәндәге санында чәчү әйләнешләре кертергә:

	Колхозлар саны	Совхозлар саны
Алтай крае	500	16
Красноярск крае	300	12
Новосибирск өлкәсе	450	26
Омск өлкәсе	500	10
Чиләбе өлкәсе	400	21
Казагстан ССР ның төньяк-көнчыгыш өлкәләре	500	30

Көнчыгыш районнарындагы барлык колхозларда һәм совхозларда чәчү әйләнешләрен кертүне өч ел эчендә төгәлләргә. Басуларны натурада кисү елын исәпләп, чәчү әйләнешләренә күчү (аларны үзләштерү) чоры кагыйдә буларак, 4 елдан артык булмаска тиеш дип билгеләргә.

7. СССР Наркомземын, СССР Наркомсовхозын, край һәм өлкә башкарма комитетларын,—колхозларда һәм совхозларда чәчү әйләнешләрен эшләү өчен бөртекле культураларның, уҗым чәчүлекләренең, күп еллык үлән һәм терлек азыгы культуралары чәчүлекләренең, чиста парларның һәм үзләштерелә торган яңа җирләрнең мәйдан күләмен өч ай срок эчендә районнарга һәм совхозларга җиткерергә мәҗбүр итәргә.

8. Көнчыгыш районнарда чәчү әйләнешләрен керткән вакытта, чәчү әйләнешләрен эшләү һәм кертү өчен „Украина ССР колхозларында дөрес чәчү әйләнешләре кертү турында" СССР Совнаркомы карарының 18 нче пунктында билгеләнгән тәртипне кулланырга.

9. СССР Наркомземын һәм Наркомхозын, Казагстан ССР Совнаркомын, өлкә һәм край башкарма комитетларын,—колхозларда һәм совхозларда чәчү әйләнешләре кертү өчен түбәндәге чараларны үткәрергә мәҗбүр итәргә:

а) чәчү әйләнешләре кертү өчен түбәндәге саннарда агрономнарның һәм җир төзүчеләрнең айлык хәзерлеген үткәрергә:

	Агрономнар	Җир төзүчеләр
Алтай крае	120	100
Красноярск крае	100	80
Новосибирск өлкәсе	130	70
Омск өлкәсе	150	50
Чиләбе өлкәсе	140	50
Казагстан ССР ның төньяк-көнчыгыш өлкәләре	175	130

б) чәчү әйләнешләре басуларын кисү буенча җир төзүчеләргә ярдәм итү өчен һәрбер колхозда кимендә ике кешене колхозның җир үлчәүчесе итеп хәзерләргә;

в) 1940 нчы елны Омск авыл хуҗалыгы институты янында техниклар-җир төзүчеләр хәзерләү буенча 100 кешелек бер еллык курслар һәм Ачинск, Төмән һәм Томск җир төзү техникумнары янында техниклар-сьемщиклар хәзерләү буенча 200 кешелек бер еллык курслар оештырырга.

10. Көнчыгыш районнардагы колхозларда һәм совхозларда сабан культураларының шактый өлешен яз көне сөрелгән җирләргә чәчү тәртибен бетерергә. 1941 нче елдан башлап сабан культураларын нигездә туңга сөрелгән һәм пар җирләренә чәчәргә һәм 1943 нче елны барлык сабан культураларын туңга сөрелгән җирләргә генә чәчүгә күчәргә дип билгеләргә.

1940 нчы елны колхозларда һәм совхозларда туңга сөрү һәм парга сөрү мәйданнарын түбәндәге күләмнәрдә расларга (мең гектарлар белән):

	Туңга сөрү мәйданы		Парга сөрү мәйданы	
	Колхозларда	Барлык системадагы совхозларда	Колхозларда	Барлык системадагы совхозларда
Алтай крае	2.120	210	866	112
Красноярск крае	810	140	500	100
Новосибирск өлкәсе	1.472	210	800	100
Омск өлкәсе	1.594	246	750	100
Чиләбе өлкәсе	1.699	320	850	213
Казагстан ССР ның төньяк-көнчыгыш өлкәләре	2.156	283	900	208

Сабан ашлыгы чәчеләчәк пар җирләренең саны кимү һәм туңга сөрелгән мәйданнар саны шактый арту уңае белән, көнчыгыш районнардагы колхозларда һәм совхозларда туңга сөрү эше 1 нче июльдә башланып 15 нче октябрьдә тәмам булырга тиеш дип билгеләргә.

Көнчыгыш районнардагы колхозларда, туңга сөрү буенча мәҗбүри заданиеләр сыйфатында, һәрбер эш аты белән сезонга кимендә 4 гектар сөрергә билгеләргә.

11. Колхозларда һәм совхозларда парга һәм туңга сөрелә торган җирләрне сай сөрүне куллануны тыярга, предплужниклы сабан белән кимендә 20—22 сантиметр тирәнлектә, ә сөрү катлавы саерак булганда—бөтен тирәнлегенә сөрелергә тиеш дип, сөрү катлавын торган саен тирәнәйтә барырга дип билгеләргә. Пар җирләрен чүп үләннәреннән чистартылган һәм йомшартылган хәлдә тотуны тәэмин итәргә, артыннан ук тырмалау белән пар җирләрендә кимендә 2—3 тапкыр культивацияләү үткәрергә.

12. Союзның көнчыгыш районнарында туңга сөрелә торган һәм пар җирләренең сөрү тирәнлеге арту уңае белән, парга һәм туңга сөрелә торган җирләрнең һәр гектарына ягулык тотуның түбәндәгечә күтәренке нормаларын билгеләргә:

Крайлар һәм өлкәләр	Тракторларның маркалары			
	СТЗ-ХТЗ	ЧТЗ лигер (Килограмм белән)	СТЗ-НАТИ (Килограмм белән)	ЧТЗ диз.
Алтай крае	20,2	16,4	16,6	10,2
Новосибирск өлкәсе	21,0	16,8	16,9	10,5
Омск өлкәсе	20,5	16,6	16,7	10,3
Чиләбе өлкәсе	20,8	16,4	16,6	10,2
Красноярск крае	21,2	17,0	17,2	10,7
Казагстан ССР ның төньяк-көнчыгыш өлкәләре	21,1	16,9	17,0	10,6

Предплужниклы сабаннар белән сөргән вакытта предплужниксыз сөрү өчен билгеләнгән нормаларга карата ягулык расходлары нормасын өстәмә рәвештә 6 процентка арттырырга.

13. Туңга сөрүдә эшләүче тракторчыларны кызыксындыру теләге белән, көнчыгыш районнардагы МТС һәм совхоз тракторчылары, акчалата билгеләнгән түләү өстенә: СХТЗ тракторында 100 гектардан, СТЗ-НАТИ тракторында—200 гектардан, газогенераторлы СТЗ-НАТИ тракторында—150 гектардан; лигроинлы ЧТЗ тракторында—320 гектардан, дизелле ЧТЗ тракторында—350 гектардан һәм газогенераторлы ЧТЗ тракторында 250 гектардан арттырып үтәлгән һәр гектар өчен 20 процент өстәмә хак алалар дип билгеләргә.

14. Барлык туңга сөрелгән һәм пар җирләрен буразна сыртларының өсте кипкән моменттан алып 3 көннән дә соңга калмыйча яз көне тырмалауны төгәлләргә. Басуларны чүп үләннәреннән чистарту өчен туңга сөрелгән җирләрне яз көне культивацияләүне киң күләмдә кулланырга. Колхозларда һәм совхозларда шакмаклап чәчү һәм тар рәтләр белән чәчү юлларын, уҗым һәм сабан игеннәре тишелеп чыкканнан соң тырмалауны һәм аларны тукландыруны кулланырга.

Һәрбер колхозда һәм совхозда башаклы сабан культураларын яз көне чәчүне чәчү эшләре башланганнан алып 8—10 эш көненнән дә соңга калмыйча төгәлләргә.

15. Ашлыкны урып-җыюны җиңеләйтү өчен колхозларга һәм совхозларга, ике сортлы сабан бодае—аеруча иртә һәм аеруча соң өлгерә торган бодайлар чәчүне такдим итәргә.

16. СССР ның көнчыгыш районнарындагы колхозларга,—колхоз бригадалары звеноларында яки бригадаларда эшләүче колхозчыларга, звенода яки бригадада билгеләнгән планнан тыш алынган бөртекле ашлыкның һәм бөртекле-кузаклы культураның һәр центнеры өчен өстәмә рәвештә 2—3 хезмәт көне язарга такдим итәргә. Иген уңышы планын арттырып үтәгән өчен язылган өстәмә хезмәт көннәрен, звено яки бригада членнары арасында, аларның һәр кайсының эшләгән хезмәт көннәренең гомуми саныннан чыгып бүләргә.

Шуның өстенә звено җитәкчесенә, звенога җитәкчелек иткән өчен, бөтен звено эшләгән хезмәт көннәренең гомуми санына карата 2—3 процент күләмендә өстәмә хезмәт көннәре язарга.

17. Көнчыгыш районнардагы колхоз бригадирларын иген уңышын күтәрү белән кызыксындыру теләге белән, колхозларга,—билгеләнгән даими түләүдән тыш ел ахрында, кырчылык бригадасы бригадирына төп культуралар буенча бригаданың иген уңышы планын 10 процентка кадәр арттырып үтәгәндә—50—60 хезмәт көне күләмендә, иген уңышы планын 10 проценттан 20 процентка кадәр арттырып үтәгәндә—75—90 хезмәт көне күләмендә һәм иген уңышы планын 20 процентка һәм аннан да күбрәк арттырып үтәгәндә—100—120 хезмәт көне күләмендә премия билгеләргә такдим итәргә.

18. Кырчылык бригадаларында һәм ындыр табакларында өсте ябулы лапасларның сыйдырышы, җыелган бөртекле ашлыкны киптерүне тәэмин итәрлек итеп һәм бөртекле ашлыкның өсте ябулы булмаган ындыр табакларында саклануына юл куймаслык итеп өсте ябулы ындыр табаклары төзүне тәэмин итәргә колхозларга такдим итәргә һәм совхоз директорларын шуңа мәҗбүр итәргә.

1940—1941 нче елларда колхозларда һәм совхозларда гади сушилкалар төзүне тәэмин итәргә, СССР Наркомземына шушы елның 15 нче маена кадәр стандарт сушилкалар типын расларга кушарга.

19. Көнчыгыш крайларның һәм өлкәләрнең край башкарма комитетларын һәм өлкә башкарма комитетларын, Казагстан ССР совнаркомын,—колхоз һәм совхоз кырлары әйләнәсендәге һәм кырлар эчендәге, кырларны саклаучы табигый полосалар сыйфатында әһәмияте булган урманнарны һәм урман полосаларын кисүне тыярга, ә урманнарны кисүдә гаепле булган кешеләрне уголовный җавапка тартырга мәҗбүр итәргә.

20. СССР Наркомземына, край һәм өлкә башкарма комитетлары белән берлектә, 1940 нчы елдан башлап Барабинск һәм Кулунда далаларында һәм Хакас автономияле өлкәсендә ирригацион эшләр үткәрү турында такдимнәр эшләүне һәм аларны шушы елның 1 нче июлендә СССР Совнаркомы янындагы Экономсоветка кертүне тапшырырга.

II.

ТРАКТОРЛАРДАН ҺӘМ КОМБАЙННАРДАН ФАЙДАЛАНУНЫ ҺӘМ АЛАРГА РЕМОНТ ЯСАУНЫ ЯХШЫРТУ ТУРЫНДА

1. СССР Наркомземын һәм Наркомсовхозын, партия, совет органнарын, МТС һәм совхоз директорларын,—1940 нчы елны һәрбер тракторның бер сезон эчендә чынлыкта эшләү нормасын 1939 нчы елны эшләгәнгә караганда кимендә 10 процентка, ә һәрбер комбайнда көнлек эш нормасын кимендә 15 процентка арттыруга ирешергә мәҗбүр итәргә.

2. Көнчыгыш районнарда СССР Наркомземын,—МТС ларның машиналар паркын тулыландыру һәм яңа җирләр үзләштерү өчен 1940 нчы елны түбәндәгеләрне аерып куярга һәм җибәрергә мәҗбүр итәргә:

Дизельле ЧТЗ тракторлары—870
Газогенераторлы ЧТЗ тракторлары—635
Карбюраторлы СТЗ-НАТИ тракторлары—1.100
Газогенераторлы СТЗ-НАТИ тракторлары—1.445
Универсаль-2 тракторлары—440
Предплужниклы 5 корпуслы сабаннар—5.295
Куак кисү сабаннары—400
Төп чыгару машиналары һәм аларга трослар—75
Бөртекле ашлык чәчкечләр—6.300
Культиваторлар—3.470
Дисклы тырмалар—700
Комбайннар—3.150

Крайлар һәм өлкәләр буенча тракторларны һәм комбайннарны түбәндәгечә бүләргә:

	ЧТЗ диз.	ЧТЗ газоген.	СТЗ-НАТИ карб.	СТЗ-НАТИ газоген.	У-2	Комбайннар
Алтай крае	225	200	230	270	50	630
Красноярск крае	—	70	170	430	40	665
Новосибирск өлкәсе	150	120	230	320	100	1.000
Омск өлкәсе	170	130	270	325	100	595
Чиләбе өлкәсе	250	115	150	100	150	260

1940 нчы елгы планга өстәмә рәвештә, яңа җирләрне үзләштерү өчен Казагстан ССР ның төньяк-көнчыгыш өлкәләренә җибәрергә: дизельле ЧТЗ тракторлары—75, карбюраторлы ЧТЗ-НАТИ тракторлары—50, предплужниклы биш корпуслы сабаннар—200, дисклы тырмалар—75, куак кисү сабаннары—50.

СССР Наркомсредмашина,—1940 нчы елгы планга өстәмә рәвештә 595 трактор җитештерергә кушарга, шулардан дизельле ЧТЗ тракторлары—190.

3. СССР Наркомземына,—хәзерге МТС ларны ваклауны искә алып 1940—1941 нче елларда 136 яңа МТС оештырырга, аларны крайлар һәм өлкәләр буенча түбәндәгечә бүлергә:

	1940 ел.	1941 ел.
Чиләбе өлкәсе	5	12
Омск өлкәсе	7	13
Новосибирск өлкәсе	10	26
Алтай крае	6	11
Красноярск крае	3	8
Казагстан ССР ның төньяк-көнчыгыш өлкәләре	8	27

4. СССР Наркомземына,—түбәндәге саннарда машина-трактор мастерскойлары төзергә, аларны крайлар һәм өлкәләр буенча болай бүлергә:

	1940 ел.	1941 ел.
Чиләбе өлкәсе	10	35
Омск өлкәсе	14	26
Новосибирск өлкәсе	13	37
Алтай крае	13	47
Красноярск крае	10	25
Казагстан ССР ның төньяк-көнчыгыш өлкәләре	8	51

5. Кыр эшләре чорында тракторларга һәм авыл хуҗалыгы инвентарена агымдагы ремонтны тәэмин итү өчен, СССР Наркомземын,—көнчыгыш районнарда 1940 нчы елның 1 нче июненә 300 күчмә автомастерской оештырырга, аларны ремонт өчен кирәкле булган инструментлар һәм башка кирәк-яраклар белән тәэмин итәргә мәҗбүр итәргә, крайлар һәм өлкәләр буенча аларны түбәндәгечә бүлергә: Алтай крае—60, Красноярск крае—30, Новосибирск өлкәсе—60, Омск өлкәсе—35, Чиләбе өлкәсе—40, Казагстан ССР ның төньяк-көнчыгыш өлкәләре—75.

6. СССР Наркомземын,—көнчыгыштагы крайларда һәм өлкәләрдә эшләү өчен 1940 нчы елны 292 инженер-механизатор, 196 агроном, 94 җир төзүче һәм 1941 нче елны 484 инженер-механизатор, 392 агроном һәм 188 җир төзүче җибәрергә мәҗбүр итәргә, крайлар һәм өлкәләр буенча аларны түбәндәгечә бүлергә:

	1940 ел.			1941 ел.		
	Инженер-механизаторлар	Агрономнар	Җир төзүчеләр	Инженер-механизаторлар	Агрономнар	Җир төзүчеләр
Красноярск крае	38	34	12	76	68	24
Алтай крае	56	29	10	112	58	20
Новосибирск өлкәсе	37	20	16	74	40	32
Омск өлкәсе	35	18	10	70	36	20
Чиләбе өлкәсе	32	29	10	64	58	20
Казагстан ССР ның төньяк-көнчыгыш өлкәләре	94	66	36	188	132	72

СССР Наркомсовхозына,—көнчыгыш өлкәләрдәге совхозларга 1940 нчы елны 77 инженер-механизатор һәм 140 агроном җибәрергә.

7. РСФСР Совнаркомына һәм СССР Наркомземына,—урта квалификацияле агрономнар һәм механиклар хәзерләү өчен көнчыгыш районнарда 1941 нче елны 3 яңа техникум ачарга, шулай ук авыл хуҗалыгы инженерлары-механизаторлары хәзерләү өчен Новосибирск авыл хуҗалыгы институты янында механизация факультеты оештыруны тапшырырга.

СССР Халык Комиссарлары Советы Председателе
В. МОЛОТОВ.

ВКП(б) Үзәк Комитеты Секретаре
И. СТАЛИН.

20 апрель, 1940 ел.

ПАРТИЯ ТОРМЫШЫ

Исем түгел, бәлки эчтәлек эшне хәл итә

Азнакай районының Кәкре елга авылында партбюро урнашкан йорт бер-бер артлы килеп торучы укытучылар һәм авылның башка интеллигенциясе, партия, комсомол һәм колхоз активы белән шыгырым тулы иде инде. Партбюро секретаре иптәш Ганиев, тагын бер тапкыр залга күз йөртеп чыкты да, чакырылган кешеләрнең килеп беткәнлегенә ышангач, болай дип белдерде:

— Иптәшләр, сезне бүген бирегә „Социалистик һәм шәхси милек“ дигән темага лекция тыңларга чакырдык. Лекция өчен сүз район прокуроры иптәш Хәбибуллингә бирелә...

Бер дә көтмәгәндә лекция булачагын ишеткәч, залда утыручылар уңайсызландылар. Арттагы рәтләрдә утыручылар арасыннан берничә иптәш: „аны бер-ике көн алданрак әйтергә кирәк иде“ дип тә куйдылар. Әлбәттә аларның бу таләпләре урынлы иде.

Ләкин монда аңа игтибар итмиләр күрәсең. Сөйләргә булгач, сөйләргә инде дигәндәй, үзенә бирелгән хокуктан файдаланып, иптәш Хәбибуллин эшкә кереште.

Лектор сүзне милекнең ничек һәм каян килеп чыкканлыгын аңлатудан башлый. Ул кешелек тарихында булып үткән җәмгыят стройлары турында сөйләп, капитализмга һәм ниһаят Бөек Октябрь Социалистик революциясеннән соң безнең илебездә урнашкан социалистик стройга килеп җитә. Капиталистик милек һәм социалистик милек турында сөйли. Хәзерге көндә безнең илебездә хуҗалыкның барлык тармакларында хөкем сөрүче социалистик милек турында аңлата.

Гомумән алганда, иптәш Хәбибуллинның лекциядә алынган темага карата бик күп материаллар укыганлыгы күренә. Ләкин лектор булган кешегә күп уку гына җитми бит. Лекция тыңлаучылар аны яхшы аңласыннар өчен, укыган материалларны лекциянең темасына карата дөрес итеп билгеле бер системага салырга, мәсьәләләрне эзлекле рәвештә сөйләп барырга да кирәк. Шул ук вакытта телнең һәм җөмлә төзелешенең гадилеге лекциянең сыйфатын яхшыртуда зур урын тота.

Иптәш Хәбибуллин исә, эшнең сыйфатына аз игтибар иткән. Ул, тема буенча куелган бер мәсьәләне аңлатып җиткермичә икенче һәм өченче мәсьәләләргә күчә. Бераздан шул ук мәсьәләләргә яңадан кайтып сөйли. Мәсәлән, „капиталистик илләрдә шәхси милек закон белән саклана“ ди лектор. Ләкин капиталистик илләрдә милекнең кемнәр кулында булуы һәм кемнәрнең милке закон белән саклануны җитәрлек аңлатмый торып, шунда ук социалистик милек һәм аны саклау турында, 1932 нче елның 7 нче август карары турында сөйли башлый.

Тыңлаучылар өчен бу мәсьәләләр җитәрлек аңлатылмый калалар, ә лектор сүзен дәвам итә. Ул Сталин Конституциясе турында сөйли башлый һәм бу Конституция нигезендә совет гражданнарының шәхси милекләре закон белән саклану турындагы мәсьәләгә күчә. Социалистик дәүләт системасында шәхси милеккә нинди урын бирелүне һәм аның формалары нинди булырга тиешлек турында сөйли.

Лекциядә цитаталар гадәттән тыш күп китерелү белән бергә, аларның кайберләре урынсыз китерелделәр. Мәсәлән, „коммунистик җәмгыяттә шәхси милек буламы һәм нинди формада була“ дигән сорауга җавап һәм дәлил итеп Маркс хезмәтеннән китерелгән цитата урынсыз иде.

Аннан соң, иптәш Хәбибуллин, лекцияне язып хәзерләнмәгән. Анда китерелгән цитаталар бик күп булу өстенә, ул аларны язып та алмаган. Шунлыктан, һәрбер цитатаны лекция вактында күп төрле китаплардан эзләп ала, һәм хәтта татарча тәрҗемәләре булганнарын да русча чыганаклардан укый.

Шулай итеп лекция ярым русча, ярым татарча итеп, бик авыр һәм кытыршы телдә сөйләнде. Бу хәл аның сыйфатын тагын да түбәнәйтте һәм тыңлаучыларны канәгатьләндерә алмады.

Монда иптәш Хәбибуллин тарафыннан ясалган лекциянең җидди кимчелекләре күрсәтелде. Иптәш Хәбибуллин бу кимчелекләрне киләчәктә бетерә аламы һәм аңа киләчәктә лекцияләр уку һәм докладлар сөйләү эшен тапшырырга мөмкинме? Һич шиксез, иптәш Хәбибуллин аларны бетерә ала һәм аңа бу эшләрне тапшырырга мөмкин. Бары тик игтибар белән һәм тагын да тырышыбрак эшләргә генә кирәк. Шул ук вакытта аңа ВКП(б) ның район комитеты тарафыннан бу эштә ныклы ярдәм дә таләп ителә. Ләкин райкомның әлегә кадәр аңа ярдәм иткәне юк.

— Райондагы докладчыларның һәм лекторларның белемен күтәрүгә ничек ярдәм итәсез. Иптәш Хәбибуллинның язма лекцияләрен тикшереп караганыгыз бармы, дигәч, райкомның пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире иптәш Ибраһимов:

— Безнең районда лекторлар юк. Хәбибуллин да лектор түгел, докладчы гына, дип җавап бирде.

Монда сүз, Хәбибуллинның докладчымы, яки лектормы икәнлеге турында бармый. Эшне исем хәл итми, бәлки эчтәлек хәл итә. Сөйләүче доклад ясыймы, лекция укыймы, һәр хәлдә аның политик яктан тотнаклы, тыңлаучыларга аңлаешлы булуы, массаларга политик тәрбия бирү, аларның политик аңлылыкларын күтәрүдә ярдәм итәрлек булуы таләп ителә. ВКП(б) ның Азнакай райкомы моңа игтибар итәргә тиеш.

З. Салахеттинов.

2 нче номерлы тегү фабрикасының партия оешмасы секретаре иптәш Д. И. Ярин партиягә яңа кабул ителгән иптәшләр белән беседа үткәрә.

И. Галиев фотосы.

Югары уңыш өчен көрәштә партия оешмасы

Партиянең Усада авылындагы (Биектау районы) башлангыч оешмасы 9 коммунисттан тора. Ул Усада авыл советына караган колхозларга җитәкчелек итә. Соңгы ике ай вакыт эчендә партия оешмасы колхоз производствосына үзенең игтибарын аеруча көчәйтте. Февраль аенда, агротехника чараларын үтәү һәм авыл хуҗалыгы инвентарена ремонт ясау эше „Новый путь“ колхозында да, „Ленинский призыв“ колхозында да начар тора иде. Партоешма бу турыда колхоз председательләренең һәм бригадирларның докладларын тыңлады һәм карарлар кабул итте. Бу карарларда колхозлардагы җитешсезлекләрне бетерү буенча практик чаралар билгеләнгән иде. „Новый путь“ колхозына ярдәм итү өчен коммунистлардан Камкалин һәм Маканов иптәшләр, ә „Ленинский призыв“ колхозына Ишмуратов һәм Гарипов иптәшләр беркетелделәр. Алар ярдәме белән колхозлар беренче мартка агротехника чаралары планын тулысынча үтәделәр.

Аннары партия җыелышында язгы чәчүгә хәзерлекнең торышы тикшерелде һәм чәчүлек орлыкны яңадан чистарту, атларны тәрбияләүне яхшырту турында карарлар кабул ителде. Ат караучыларга практик күрсәтмәләр бирелде. Шушы чараларны тормышка үткәрү нәтиҗәсендә бу тармакта да эш яхшырды.

Партия оешмасы колхозчылар арасында массовый-политик эшне киң җәелдерде. Коммунистлардан Камкалин, Никулин һәм Маканов иптәшләр һәм партиясез агитатор Игнатьев иптәш „Новый путь“ колхозында, ә Ишмуратов һәм Мурзина иптәшләр „Ленинский призыв“ колхозында масса-аңлату эше алып баралар.

Колхоз членнарының гомуми җыелышларында һәм бригадаларда иптәш Молотовның СССР Верховный Советының VI нчы Сессиясендә ясаган докладын һәм Сессия карарларын өйрәндек. Бригадаларда стена газеталары чыгарыла. Партия оешмасы авыл активы белән һәм авыл хәбәрчеләре белән берлектә чәчүгә хәзерлекне тикшерү буенча эшче-авыл хәбәрчеләре рейде үткәрде. Эшче-авыл хәбәрчеләре бригадасы тарафыннан ачылган кимчелекләр колхозчыларның гомуми җыелышларында тикшерелде һәм аларны бетерү буенча чаралар күрелде.

Партия оешмасы чәчү вактына партия-масса эше алып бару өчен план төзеде. Бу планда һәрбер коммунистка аерым задание бирелде. Мәсәлән, иптәш Мурзина „Ленинский призыв“ колхозында кычкырып газета укулар үткәрә һәм стена газетасы чыгара. Иптәш Ишмуратов шул ук колхозда политинформацияләр ясый.

Без язгы чәчүне 5—6 көндә тәгәлләргә билгеләдек. Чәчү вактында барлык коммунистлар бригадаларда, звеноларда эшлиләр һәм алар производство эшендә бригадирларга һәм звено җитәкчеләренә ярдәм итәләр.

Нури Гаффаров.

Партиянең Усада авылындагы башлангыч оешмасы секретаре.

ЯШ КОММУНИСТЛАР КИҢӘШМӘСЕ

Шушы көннәрдә, ВКП(б) ның Арча райкомы 4 урында яш коммунистларның киңәшмәләрен үткәрде. Анда 70 тән артык кеше катнашты. Киңәшмәдә халыкара хәлләр, яш коммунистларның бурычлары турында докладлар куелды һәм ВКП(б) ның уставы өйрәнелде.

Киңәшмәгә катнашучы иптәшләр ВКП(б) райкомының оештыру-инструкторлык бүлеге һәм партиянең башлангыч оешмалары тарафыннан аларга игтибарның җитәрлек булмавы турында сөйләделәр.

Райфо янындагы башлангыч оешмада ВКП(б) сафларына яңа алынган 5 иптәшнең 2 се берничә партпоручение алып бара, ә башкаларына бер төрле дә поручение бирелмәгән. Бу оешмада поручение үтәүдә яш коммунистларга ярдәм һәм аларның эшләренә контроль һич тә канәгатьләнерлек түгел.

Киңәшмәгә катнашучы иптәшләр башка партоешмаларда да мондый җитешсезлекләрнең яшәп килүен күрсәттеләр.

Мөхәммәдиев.

АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ АЛДЫНГЫЛАРЫНЫҢ РЕСПУБЛИКА КҮЛӘМЕНДӘГЕ ПОЧЕТ ТАКТАСЫ ТУРЫНДА

ВКП(б) ӨЛКӘ КОМИТЕТЫ БЮРОСЫ КАРАРЫ

ВКП(б) Өлкә Комитеты бюросы карар бирә:

1. „Кызыл Татарстан“ һәм „Красная Татария“ газеталары битләрендә авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика күләмендәге почет тактасын оештырырга.

2. Республика күләмендәге почет тактасына язгы чәчүдә югары хезмәт җитештерүчәнлеге һәм эштә югары сыйфат күрсәткәнлеге биргән авыл хуҗалыгы алдынгылары, ВКП(б) райкомнары һәм район башкарма комитетларының күрсәтүләре буенча кертеләләр дип билгеләргә.

3. Республика күләмендәге почет тактасына кертү материалларын карауны Матвеев, Киселев, Черзор, Саланов һәм Зыбин иптәшләргә тапшырырга.

ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитеты секретаре А. АЛЕМАСОВ.

Райком һәм производствога контроль мәсьәләсе

Октябрь райкомының 7 нче апрельдәге утырышында сүз В. Поляна колхозы партоешмасының производствога ничек контрольлек итүе турында барды.

Бу мәсьәлә буенча башлангыч партоешма секретаре иптәш П. Давыдовның докладыы тыңланды. Партия оешмасы хуҗалык мәсьәләләре белән сирәк һәм бик сәтән генә шөгыльләнә. Партоешма отчет-сайлаулардан соң терлекчелек эше һәм язгы чәчүгә хәзерлек турында колхоз председателенең ике тапкыр информациясен тыңлап, карарлар кабул итү белән генә чикләнгән. Ул карарларны үтәү эше оештырылмаган; алар кәгазьдә генә калганнар. Колхозда җидди җитешсезлекләр яшәп килә. Колхозның бригадаларында һәм звеноларында хезмәтне оештыру һәм политик-масса эшләре начар тора.

Колхоз производствосына контрольлек итүнең болай начар торышының төп сәбәпләрен, бу оешманы тикшерүче инструктор иптәш Туйдулов бюрода тулы ачып салыр дип көтелгән иде. Ләкин алай булып чыкмады. Ул, колхозда эшнең начар куелуын, карарларның үтәлмәвен гомумән генә әйтү белән канәгатьләнде.

Үзенең контрольлек функциясен тулы үтәү өчен В. Поляна партоешмасы нинди мәсьәләгә ныграк игтибар бирергә тиеш соң? Утырышта менә бу иң кирәкле момент тиешенчә ачып бирелмәде, колхозның барлык төрдәге эшләре буенча гомуми күрсәтмә бирү белән генә чикләнелде. Доклад буенча кабул ителгән карар „җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерүне тәэмин итәргә“ дигән берничә гомуми пункттан гыйбарәт булды.

Башлангыч партоешманың контрольлек итү эшендә төп кимчелеге—производство мәсьәләләре турында гомуми докладлар тыңлау белән генә чикләнүендә. Колхозның артта баруын бетерүдә хәл иткеч урын тоткан эш тармагы турында конкрет рәвештә куелмый, колхоз правлениесенә тегә яки бу эшне яхшырту буенча конкрет күрсәтмәләр бирелми һәм җыелыш карарларын үтәү өчен системалы көрәш оештырылмый. Шунлыктан, партоешмада производство мәсьәләләренең куелышы бик формаль булып чыга һәм карар да үтәлми кала. Хәзер бу өлкәдә кискен борылыш булдыру өчен партоешманың төп игтибарын, барыннан да элек, колхозның хәл иткеч участокларына партия һәм комсомол көчләрен дөрес урнаштыруга, оператив җитәкчелек итүгә, производствода хезмәт дисциплинасын ныгытуга, политик-масса эшен планлы тәртиптә оештыруга юнәлдерергә кирәк.

Райком хәзерге вакытта колхоз партоешмалары өчен бик кирәкле булган бу актуаль мәсьәләне бюро утырышында куеп яхшы эшләде. Ләкин ул әле башка башлангыч оешмаларда да сабак бирерлек итеп алып нык хәзерләнмәгән иде. Колхоз һәм МТС партоешмаларында производствога контрольлек итү эшенең торышы турындагы мәсьәләләрне утырышка кую алдыннан аңа ныклап хәзерләнергә, контрольлек итү эшен начар алып баручы башлангыч оешма секретарен гына түгел, бәлки яхшы оештыручы секретарьларны да утырышка чакыруны һәм тәҗрибәләрне уртаклашуны кулланырга кирәк.

Районда колхоз партоешмаларының күбесендә производствога контрольлек итү эше ныклы юлга куелмаган әле. Мәсәлән, „Кызыл Көн“ һәм Нәриман исемендәге колхозларда, шулай ук МТС та производствоның хәл иткеч тармакларына партия һәм комсомол көчләрен урнаштыру, хезмәт дисциплинасын ныгыту, социалистик милекне саклау өчен көрәш мактарлык тормый. ВКП(б) райкомы производство типындагы башлангыч партоешмаларда хуҗалык эшләренә контрольлек итү эшен кискен рәвештә яхшырту чарасын күрергә, бу мәсьәлә белән көндәлек рәвештә шөгыльләнергә тиеш.

У. Ахметов.

ҖИҢЕЛ ПРОМЫШЛЕННОСТЬ КАДРЛАРЫ

Орденлы республикабызның җиңел промышленносте 1940 нчы елның 1 нче квартал планын арттырып үтәде. Шуның белән бергә, продукциянең сыйфаты да сизелерлек рәвештә яхшырды.

Уңышларны техниканы үзләштергән, тәҗрибәле, квалификацияле кадрлар хәл итәләр. Кадрларның белем дәрәҗәләрен күтәрүгә зур средстволар тотыла. Җиңел промышленность предприятиеләре буенча үткән елны техминимум түгәрәкләрендә 2.471 кеше укыды. Стахановчылар мәктәбендә 51 кеше укыды. ФЗУ мәктәбен 78 кеше тәмам итте. Москвада, Ленинградта һәм башка эре шәһәрләрдә 38 кеше укыды һәм алар инженер-техник работниклар булып әверелделәр. Моннан тыш, Казан филиалында 62 кеше укыды. 90 кеше шоферлар, электромонтерлар хәзерләү курслары аша үттеләр. Финанс работниклары хәзерләү курсларын 41 кеше тәмам итте.

Стахановчыларның тәҗрибәләрен уртаклашу буенча практик чаралар күрелә. Алдынгы стахановчыларның эш методларын үзләштерү, аларның бай тәҗрибәләреннән файдалану теләге белән кыска сроклы курслар оештыру практикасы киң кулланыла. Мондый курслар аша 674 кеше үтте инде.

Быел техминимум аша 1.500 кеше үтәргә тиеш. 1 нче кварталда техминимум аша 400 кеше үтте. ФЗУ мәктәбендә 140 кеше укырга тиеш. 1 нче кварталда 76 кеше ФЗУ мәктәбен тәмам итеп чыкты. Стахановчылар мәктәбендә 46 кеше укый.

Стахановчыларның тәҗрибәләрен өйрәнү буенча предприятиеләрдә 400 группа оештырылды. Бу группаларда 2.000 кеше укый. Җиңел промышленность предприятиеләрендәге кадрларның квалификацияләрен күтәрү өчен быел 750 мең сум акча тотылачак.

Җиңел промышленность системасында йөзләрчә работниклар җитәкче эшләргә күтәрелделәр. „Спартак“ комбинатында үткән елны 43 кеше производствоның җаваплы участкыларына куелдылар. Мәсәлән, иптәш Маслов башта гади эшче булып эшләде. Яхшы эшләгәне өчен, хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү буенча зур дәрт һәм энергия белән көрәшкәне өчен комбинат җитәкчеләре аны бригадир итеп күтәрәләр. Бригада членнарының эшләренә ул бөтен чаралар белән булыша, аларны катлаулы процесста эшләргә өйрәтә, социалистик ярышка якыннан торып җитәкчелек итә. Бригада тизлек белән алга бара һәм алдынгылар сафына чыга.

Иптәш Маслов үзенә булган ышанычны тулысынча аклый. Аны мастер итеп күтәрәләр. Хәзер аңа тагын да җаваплырак эш тапшырылды—ул парусин цехы начальнигы булып эшли. Иптәш Глоцер башта гади эшче, аннан соң мастер, ә хәзер цех начальнигы. Иптәш Шаһвалеева—элекке фрезеровщик, хәзер парусин цехында мастер. Стахановчы иптәш Мөхәммәтҗанов АГО цехы мастеры. Элек цех начальнигы иптәш Ситников хәзер комбинат директоры булуга кадәр үсте. Комбинатта алар аз түгел. Күтәрелгән работниклар үзләренә тапшырылган гаять җаваплы бурычларны намус белән башкаралар. Комбинат коллективы 1940 нчы елның 1 нче квартал планын 102,6 процент итеп үтәде.

Работникларның тизлек белән үсә баруларын 5 нче тегү фабрикасында да күреп була. Биредә җитәкче работникларның барсы да диярлек түбәннән күтәрелгән кешеләр. Плановик иптәш Бакирова фабрика директоры итеп, эшче иптәш Ширяева техник директор итеп, эшче иптәш Рожкова мастер итеп, эшче иптәш Насыйрова цех начальнигы ярдәмчесе итеп күтәрелделәр. Алар хезмәткә аңлы карашның үрнәген күрсәтәләр, кадрлар үссеннәр, хезмәт җитештерүчәнлегенең әлегәчә күрелмәгән күтәрелешен тудырсыннар өчен алар бөтен чараларны күрәләр. Производствога яңа килеп эшләүчеләр биредә аз түгел. Күтәрелгән работниклар яңа эшчеләрне игтибар белән күзәтәләр, аларның квалификацияләрен күтәрү өчен практик чаралар күрәләр.

Җитәкчелектәге бу стиль производствода гомуми күтәрелешкә алып бара. Фабрика 1 нче квартал планын 116,4 процент итеп үтәде.

Җиңел промышленность предприятиеләрендә уңышлар аз түгел, әлбәттә. Ләкин җитешсезлекләр дә бар әле. Бу наркоматның иң эре предприятиеләреннән берсе булган „Кызыл тукучы“ фабрикасы гомумән артка калып килә. Ул 1 нче квартал планын бары 94 процент кына үтәде. Сукно фабрикасына карата да шул сүзне әйтергә кирәк. Ул 1 нче квартал планын бары 91 процент кына үтәде.

Бу предприятиеләрнең эшендә төп кимчелек шунда: кирәк „Кызыл тукучы“ фабрикасында булсын, кирәк сукно фабрикасында булсын,—кадрлар турында, аларның квалификацияләрен туктаусыз үстерә бару турында чын-чынлап кайгырту җитми. Сукно фабрикасы җитәкчеләре, партия һәм профсоюз оешмалары эшчеләрнең квалификацияләрен күтәрү турында күп сөйләнәләр, ә эшкә килгәндә аларның күбесе үтәлми.

Җиңел промышленность наркоматы исә мондый артка калып барган предприятиеләргә аерым рәвештә якын килә белми, аларны көндәлек контроль һәм җитәкчелек астына алмый. Бу кимчелекне бетерергә, кадрларның техник һәм гомуми белем дәрәҗәләрен күтәрү эшен планлы тәртиптә алып барырга кирәк.

Г. Сәет.

1 нче МАЙ АЛДЫ ЯРЫШЫ

СТАХАНОВЧЫ ВАХТАГА БАСТЫЛАР

Өченче номерлы фанер заводы стахановчылары 1 нче Майны производствода яңа җиңүләр белән каршылау өчен көрәшәләр. Заводның төп производстволары апрель ае планын арттырып үтәү өчен яңа йөкләмәләр алдылар. Һәм алган йөкләмәләрен намус белән үти башладылар.

Каезлау станокларында эшләүче Садыйков, Рәхмәтуллин, Фәхреттинов һәм Гыйлманов иптәшләр җитәкчелек итә торган бригадалар стахановчы вахтага бастылар. Бу бригадалар көнлек норма үтәлешен 167—173 проценттан киметмиләр. Шул ук цехта эшләүче иптәш Гыйззәтуллин норманы ике ярым—өч тапкыр арттырып үти. Утиль цехы эшчеләреннән Зинин, Федотов һәм Сергеева иптәшләр аеруча яхшы эшлиләр. Бу иптәшләр үзләренең нормаларын 207—290 процент итеп үтәүне көндәлек эштә ныгыттылар.

Цех, бригада һәм аерым эшчеләрнең ярышта алган йөкләмәләренең үтәлешен тикшерү эше оештырылды.

И. Фәйзуллин.

ЯРЫШ АЛДЫНГЫЛАРЫ

14 нче трестның агач материаллары эшләү комбинатында Беренче Май алды ярышы киң җәелә. Стахановчылар хезмәт җитештерүчәнлегенең югары үрнәкләрен күрсәтәләр. Стахановчы иптәш Бикчантаев норманы һәр вакыт ике тапкыр арттырып үти. Ул яхшы сыйфатлы продукция җитештерә. Хатын-кызлардан Бачкисова һәм Әхметшина иптәшләр үзләренең нормаларын 200 процент итеп үтәүгә ирешәләр.

Стахановчылар производствоны яхшырту мәсьәләләре белән системалы рәвештә шөгыльләнәләр. Алдынгы стахановчы һәм Казан Шәһәр Советы депутаты иптәш Минәев рамнарны эшләү өчен электр көченнән файдалану турында кыйммәтле тәкъдим бирде. Аның бу тәкъдиме хезмәт җитештерүчәнлеген 18 процентка күтәрә һәм 7 мең сумнан артык экономия бирә, әйбернең үзенә төшү бәясен 70 процентка кадәр арзанайта.

Иптәш Ершов тарафыннан бирелгән тәкъдим дә бик файдалы. Аның тәкъдиме хезмәт җитештерүчәнлеген 20 процентка кадәр күтәрә, 10 мең сум экономия бирә һәм продукциянең үзенә төшкән бәясен 21 процент арзанайта.

Соңгы көннәрдә комбинат киң куллану товарлары җитештерү процессын үзләштерү буенча практик эш алып бара. Быел 2 миллион сумлык киң куллану товарлары җитештереләчәк.

З. Гәрәй.

ТИЗ ҺӘМ ЯХШЫ ИТЕП ЧӘЧӘРГӘ

АКТАНЫШТА ЯХШЫ ЧӘЧӘЛӘР

(Махсус хәбәрчебездән)

АКТАНЫШ. (Телефон буенча). Районда кояшлы матур җылы көннәр тора. Агыйдел ничек ямьле, ничек гүзәл ташыган булса, колхоз басулары да шулай ук ямьле. Барлык халык басуда. Бөтен тормыш кырларга күчкән. Анда уныш өчен көрәш бара. Алдынгылык өчен чын мәгънәсе белән ярыш бара.

Актаныш районы колхозлары соңгы көннәрдә бик зур эш башкарганнар. Иртә культуралар чәчү планы 40 процент чамасы үтәлгән инде.

22 нче апрельдә „Трактор" колхозы иртә культуралар чәчүне тәгәлләде. Бу культураларны чәчү эшен „Яңа тормыш", „Изаил", „Лена", „Озын Кул", „Спартак", „Урак" һәм Куйбышев исемендәге колхозлар да бүген-иртә тәгәлләп торалар.

Бу колхозлар чәчү сыйфатын җиренә җиткереп эшлиләр. Гомумән Актаныш районы яхшы чәчә. Колхоз кырлары сокланырлык матур. Ужымнар яшел хәтфә булса, сабан басулары шомырт шикелле кара. Басуда чүпнең заты да юк. Чиста һәм пөхтә итеп эшләнгән, әйе, монда чынлап та җирнең кадерен беләләр, диясе килә. Җирнең кадерен белгән колхозлар, мәсәлән, „Урак", „Кызыл Кеч" һәм башкалар мул торалар, чәчүлек белән башка колхозларга да зур ярдәм итәләр.

Район колхозлары чәчүдән тыш та күп нәрсә эшләгәннәр. Орденлы Актаныш МТС ның тракторчылары 3 мең гектар чамасы язгы сөрү үткәргәннәр. 19 мең гектар тырмаланган, 9 мең гектарда культивация уздырылган, 1.800 гектар ужым тырмаланган. Ужым тырмалау һәм мульчирование эшләре [illegible] бара.

Актаныш районының язгы чәчүгә республикабызның алдынгы районнары белән бер рәттән тәмам итү өчен, тагын да матур сыйфатлы [illegible] өчен мөмкинлекләр бар.

Х. Фәтхуллин.

Хатын-кыз тракторчылар үрнәк күрсәтәләр

Столбище МТС ының хатын-кыз тракторчылар бригадасы кыр эшләренең беренче көннәрендә үк яхшы эш үрнәкләре күрсәтә. Отрядта 10 тракторчы эшли. Шулардан Филиппова һәм Полякова иптәшләр производстводан аерылмыйча укып, әле быел гына тракторчы булып чыкканнар.

Кырга чыгуның беренче көненә үк бригада көнлек заданиене арттырып үтәде. Тракторчы иптәш Храмова 4,5 гектар урынына 5,8 гектар сөрде. Комсомолка Федосеева, Семенова, Кондратьева, Коннова иптәшләр быел ук сменаларында 7 шәр гектар эшләргә йөкләмә алдылар.

Бригадада вакыттан дөрес файдалану, тракторларның эшсез тукталып тормауларына һич әһәмият бирелә. Бригадада көндәлек эш өчен расписание бар. Һәр көн иртән сәгать 6 да тракторларга заправка ясала. Икенче сменада эшләячәк тракторчы беренче сменада эшләүчеләрдән тракторны җентекләп тикшереп кабул итә. Смена алышынган арада учетчы эшләгән эшне учетка ала.

Бригада өчен төрле газета-журналлар язылырган. Тракторчылар үзләренең буш вакытларын культуралы итеп үткәрү белән бик кызыксыналар. Ләкин бу бригада эшли торган Ворошилов исемендәге колхоз (председателе иптәш Поляков) тракторчыларга уңайлы шартлар тудыру белән кызыксынмый. Бригадада торак вагон юк, шунлыктан тракторчылар авылга кайтып куналар.

Попов.

СОВХОЗ КЫРЛАРЫНДА

Тымытык районының Вахитов исемендәге совхозында кыр эшләре киң җәелде. Совхозда 735 гектар бөртекле культуралар чәчелде, 2.850 гектар тырмаланды һәм 1.118 гектар культивацияләнде инде. Барлык участокларга да чиста сортлы орлыклар гына чәчелә.

Совхозда социалистик ярыш һәм стахановчылык хәрәкәте киң колач ала. Стахановчы иптәш Х. Хафизов дизельне тракторда нормасы 200 процент итеп үти. Х. Газизова һәм Х. Әхмәтшин иптәшләр тунга сөрелгән җирләрне культивацияләүдә норманы 200—203 процент итеп үтиләр.

Совхозда чәчүдә эшләүче эшчеләргә культура, көнкүреш хезмәте күрсәтү яхшы оештырылган. Кырлардагы культура вагоннары радиолаштырылган, әдәбият һәм музыка инструментлары белән тәэмин ителгән. (ТатТАСС).

МТС тракторларының эше турында Татарстан Җир Эшләре Халык Комиссариаты сводкасы

1940 нчы елның 20 нче апреленә

(15 ат көчле һәр трактор белән эшләнгән эш гектарлардан)

МТС лар	Гектар	МТС лар	Гектар	МТС лар	Гектар
Көньяк-көнчыгыштагылар		*Төньяктагылар*		Кызыл Чапчак	11,5
Тымытык	53,0	Нөркәй	52,3	Чистай	11,0
Чаллы	53,2	Актаныш	44,3	Ст. Тимошкино	10,7
Сарман	45,0	Тел. Тамак	39,5	Тат. Ялтан	10,5
Кәкре Елга	39,8	Минзәлә	29,6	Куйбышев	10,1
Әлмәт	29,7	[illegible]	26,5	Зирекле	9,5
Бөгелмә	28,1	[illegible]	23,3	[illegible]	8,8
Кучү	18,0	[illegible]	17,8	[illegible]	8,4
Сукояка	15,3	[illegible]	12,8	Барлыгы	6,8
Заинский	14,9	Алабуга	9,1	*Көнбатыштагылар*	
Чыбыклы	14,3	Барлыгы	6,9	Тәтеш	8,4
Шөгер	14,1	*Кама артындагылар*		Буинский	8,3
Иске Писмән	12,5	Каргалы	17,7	Чүри бураш	4,4
Баулы	10,6	Черемуховский	17,6	Тархан	4,3
Карабаш	10,7	Базарлы Матак	16,5	Столбище	2,9
Азнакай	8,4	Мөслим (Чистай)	15,3	[illegible]	1,2
Поповский	8,4	Аксубай	12,7	МТС лар буенча барлыгы	18,5
Чишмә	6,3	Кузнечиха	11,9		
Үзәк	4,7	Октябрь	15,7		
Барлыгы	18,5				

ЯГУЛЫКНЫ ЭКОНОМИЯ БЕЛӘН ТОТАРГА

Быел Татарстан АССР колхозлары басуларында 12 мең чамасы машина эшләячәк. Алар өчен 82 мең тонна керосин, бензин һәм лигроин кирәк. Бу хәл, МТС ларның барлык работникларыннан, ягулык материалларыннан файдалануда нык экономия белән эш итүне таләп итә.

Тракторның отстойнигын яхшылап карамау аркасында гына да бер эш көнендә һәр трактордан 2 килограммнан артык ягулыкның югалуы мөмкин. Ә бу санны барлык машиналар санына тапкырласак гаять зур сан килеп чыга, 24 мең килограмм була.

Үткән елны Татарстан АССР МТС лары ягулыкка 1.510 тонна экономия ясадылар. Бу, тотылырга тиеш булган ягулыкның 1,5 процентын тәшкил итә. Ләкин шул ук вакытта кайбер МТС лар ягулыкны кирәгеннән артык тоттылар. Кирәгеннән артык тотылган ягулык 751 тоннага җитте.

Орденлы Актаныш МТС ы үткән елны ягулыкка 72,4 тонна, Исәнбай МТС ы—56,5 тонна, Тымытык МТС ы—62,1 тонна, Базарлы Матак МТС ы—49,7 тонна экономия ясадылар. Ә менә Димитров исемендәге МТС та 20 тонна, Беренче Май МТС ында 52,4 тонна, Тат. Ходяш МТС ында 43,4 тонна, Зөя МТС ында 36,8 тонна, Буа МТС ында 33,7 тонна ягулыкны артык тоттылар.

Өч республика арасында төзелгән социалистик ярыш договоры буенча без быел ягулык материалларын планга карата 3 процент кимрәк тотарга тиешбез. Бу йөкләмә һич шиксез үтәлерлек.

Ягулык һәм майлау материалларын экономия белән тоту өчен көрәш, барыннан да элек, тракторларга техник уходны дөрес куюга бәйләнгән.

Эшкә керешү алдыннан барлык тракторларның да карбюраторларын тикшерергә һәм аларны дөрес эшләрлек итеп көйләргә кирәк. Начар сыйфатлы итеп ремонт ясалган һәм дөрес итеп көйләнмәгән карбюратор ягулыкның 20 процепттан артык тотылуына сәбәп була.

Карбюраторларда нинди төп кимчелекләр була соң? Алардагы түбәндәге төп кимчелекләр ягулыкның артык тотылуына илтәләр:

Төп жиклерның көйләү винты белән трубкасы арасындагы зазорның стандарт күләмгә караганда зуррак булуы. Кайбер карбюраторларда бу зазор 0,60—0,70 миллиметрга кадәр зурайган була. Ә асылда нормаль зазор 0,30 миллиметр булырга тиеш.

Распылитель юлларының пычранган булуы. Дроссель заслонкасының дөрес көйләнмәве. Игольчатый клапанга яхшылап притирка ясалмавы.

Испарительнең суыргыч трубаларына кокс утыру бигрәк тә зарарлы нәрсә. Әнә шул кимчелек булу нәтиҗәсендә генә дә двигатель көченең 6—7 ат көченә кимүе һәм ягулыкның кимендә 15—20 процент артык тотылуы мөмкин.

Хәзерге вакытта испарительнең суыргыч трубаларын чистарту өчен бик гади бер метод табылды. Моны кислород ярдәме белән мастерскойның үзендә дә һәм кыр шартларында да башкарырга мөмкин. Трубаны чистарту түбәндәгечә эшләнә: труба эче керосин белән чылатыла һәм труба эченә янып торган бер кисәк агач күмере куела. Аннан соң 5 нче номерлы горелка ярдәме белән 5—6 атмосфера басымлы кислород (ацетиленнан башка) бирелә. Шуннан соң 8—10 минут эчендә үк трубадагы кокс янып бетә. Шуннан соң труба металл цетка белән чистартыла.

Ягу аппаратурасының тәмам төзек булуын тәэмин итәргә кирәк. Тракторның ягулык белән туклану системасын (трубалар, отстойниклар һ. б.) даими рәвештә тикшереп торырга кирәк.

Һава чистарткычларның төзек булуына бик нык әһәмият бирергә, суыту системасын юшкыннан һәр вакыт чистартып торырга, клапаннарны дөрес көйләргә кирәк. Тагылма машиналарның торышы һәр вакыт күзәтеп барылырга тиеш. Бигрәк тә сабан тәрәннәренең дөрес утыртылган булуларына, аларның үткен булуларына әһәмият бирергә кирәк. Сабан тәрәннәре үтмәс булсалар тракторны 4—5 ат көченә артыграк көч белән эшләтергә туры килә. Ә бу исә ягулыкның артык тотылуына илтә.

Кыр станында ягулыкның бик ныклап саклануын тәэмин итәргә, ягулык тутырылган мичкәләрне кую өчен өсте салам маталар, яисә каплар белән ябылган махсус шалашлар булдырырга, тракторга ягулык салуны буразнада ук башкарырга, тракторны көйләү өчен кирәкле барлык инвентарьларны булдырырга кирәк.

Болар барлыгы да ягу һәм майлау материалларына экономия бирәләр.

С. В. Резяпкин.

Татнаркомземның баш инженеры.

ЧӘЧҮГӘ СОҢГА КАЛУНЫ КИЧЕКМӘСТӘН БЕТЕРЕРГӘ

Быел яз үткән елдагыңа чагыштырганда 10 көн чамасы алданрак килде. Быел язның килешендә температура ягыннан да һәм шулай ук дым төшү ягыннан да күрнеш тәмам нормаль. Татарстан АССР да масса күләмендә чәчү 22—23 апрельдә башланды дип исәпләргә мөмкин.

Күп кенә районнар чәчү эшләрен җитез алып баралар. Мәсәлән, Тымытык районы 20 нче апрельгә язгы чәчү планын 39,1 процент үтәде, яисә башаклы культураларның 57,5 процентын чәчте. Мөслим, Калинин һәм башка берничә район шулай ук чәчү эшләрен яхшы темп белән алып баралар. Ә менә шул районнар белән чиктәш булган һәм климат-туфрак ягыннан бер үк шартларда булган Акташ, Беренче Май, Бөгелмә, Октябрь һәм башка күп кенә районнар язгы чәчү эшләрен чиктән тыш акрын җәелдерәләр. Бу районнарда шул ук 20 нче апрельгә чәчү планы бары 4 проценттан 9 процентка кадәр генә үтәлгән.

Күп кенә районнарда туфрак хәзерләү белән чәчү эше арасында зур өзеклек булуын, әзерләнгән туфрак була торып чәчү эшләренең акрын баруын әйтергә кирәк. Мәсәлән, Бөгелмә районында 20 нче апрельгә тик тракторлар белән генә дә хәзерләнгән 4.059 гектар җир бар. Шуның бары 3.500 гектарына гына чәчелгән. Биләр һәм Әлки районнарында да туфрак эшләү белән чәчү арасында өзеклек шактый зур. Чәчү эшләренә күптән керешүгә дә карамастан, Биләр районында чәчү планы бары 1,9 процент, Әлки районында бары 1,2 процент кына үтәлгән әле.

Быел ужымнар кар астыннан яхшы хәлдә чыктылар һәм бик тиз үсә башладылар. Кар астыннан начар хәлдә чыккан ужымнар да, һава бик яхшы булу нәтиҗәсендә, бик тиз хәл алдылар. Ләкин, ужымнарны тәрбия итүнең бөтенләй канәгатьләнмәслек булуын әйтергә кирәк. Ужымнарны тәрбияләү язгы кыр эшләре белән, иртә культураларны чәчү белән бер үк вакытта барырга тиеш иде. Ә менә Заинский районында язгы чәчүгә масса күләмендә керешкән 50 колхозның әле берсендә дә ужымнарны тәрбия итү эшенә керешкәннәре юк. Ужымнарны тәрбия итү Зөя МТС ы колхозларында, Яңа Чишмә, Беренче Май, Алабуга һәм башка күп кенә районнарда да бик акрын бара. Ужымнарны тәрбия итүдә артта калуны кичекмәстән бетерергә кирәк. Ужымнарның хәле никадәр генә яхшы булса да тәрбиягә бик мохтаҗ булуларын истән чыгарырга ярамый.

Күп еллык үләннәр чәчү ачыктан-ачык, соңга калу, хәтта өзелү куркынычы алдында тора. 20 нче апрельгә республикада бары 4.669 гектар чәчелгән әле. Үлән чәчү эшләрен тизрәк тәгәлләү эшенә Балтач, Мамадыш, Балык Бистәсе, Буа һәм Тархан районнары бөтенләй игтибар бирмиләр, бу эшне өзелү куркынычы алдына куялар.

Техника культураларыннан көнбагыш һәм долгунец җитен чәчү дә бик акрын бара. Хәтта бу культура орлыкларының шактый өлеше Заготзерно пунктларыннан да кайтарылмаган. Техник культураларга карата җансыз карашны кискенлек белән бетерергә кирәк.

МТС ларның да күпчелеге кыр эшләренә керештеләр. Сарман, Нөркәй, Мөслим, Актаныш, Тымытык, Кәкре Елга, Тәтеш МТС лары алда баралар. Ә менә Калинин, Октябрь, Темошкино, Үзәк, Заинский, Баулы һәм башка кайбер МТС лар һаман да бик акрын кыймылдыйлар. Күп кенә МТС ларда техник уход начар булганлыктан тракторларның шатун подшипниклары эрү кебек аварияләр соңгы көннәрдә бигрәк тә еш күренә башлады. Язгы кыр эшләренә керешкәннән соң Калинин МТС ында 18, Алексеевский МТС ында 5, Кузнечиха МТС ында 6, Чиябаш МТС ында 6, Каргалы МТС ында 8, Мәлки МТС ында 6, Майдан МТС ында 5 тракторның подшипникларын эреттеләр.

Бу кимчелеккә бүгеннән үк чик куярга, тракторлардан дөрес, тулысынча һәм һичбер авариясез файдалануны тәэмин итәргә кирәк.

Шулай ук күп кенә колхозларда агротехника кагыйдәләрен төгәл үтәүгә дә әһәмият бирүнең җитәрлек булмавын күрсәтте. Мәсәлән, Кама Тамагы районының „Пятилетка" колхозында бодайның бер өлешен формалинны ике доза салып агулаганнар, ә шул ук районның „Совместный труд" колхозында ике гектарга бодайны бөтенләй агуламый чәчкәннәр. Столбище районының „Красный Армеец" һәм Калинин исемендәге колхозларында да агуланмаган орлык белән чәчү фактлары барлыгы беленде. Яңа Чишмә районының Крупская исемендәге колхозында тракторлар белән бары 12 сантиметр тирәнлеккә сөреп җир бозулары һәм тракторларга бары атлы ике сабан тагып йөреп тракторларны яртылаш нагрузка белән генә эшләтүләре билгеле булды. Сай сөрү фактлары Биләр районының „Малалла", Чистай районының „Красный партизан" колхозында да барлыгы ачылды.

Язгы чәчүне мөмкин кадәр кыска срокта үтәү өчен көрәшү белән бер рәттән сыйфат өчен көрәшүне дә истән чыгарырга ярамый. Язгы чәчү эшләре иң яхшы сыйфат белән үткәрелергә тиеш.

Климат шартлары яхшы булу бер үзе генә югары иген уңышын бирми. Югары иген уңышы яулап алына ул. Басуларда Беренче Май алды ярышын киң җәелдерергә, чәчү темпын күп тапкырлар көчәйтергә кирәк.

В. И. ЛЕНИННЕҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ ТУЛУГА КАРАТА

БӨЕК ҮРНӘК

Москва! Ул безнең киң илебезнең генә башкаласы түгел. Ул бөтен дөнья революциясенең йөрәге.

Аның, Кызыл Мәйданында безнең юлбашчыбыз, Социалистик революциянең маршалы, тау бөркете, бөек Ленин йоклый. Илнең төрле почмакларыннан килгән төрле милләт халыклары әнә шул мәйдандагы гранит мавзолей аша үтеп торалар. Алар бер-беренә аңлашылмый торган телләрдә һәрберсе өчен уртак, һәрберсе өчен якын сүзне кабатлыйлар:

— Ленин!

— Ленин!

— Ленин!

Алар ерак җирләрдән алып килгән халыклар сәламен, меңләгән йөрәкләр рәхмәтен юлбашчы янында калдырып чыгалар. Алар алгы көрәшләр өчен юлбашчының пыяла табуты янында ант итәләр.

Һәм аннан чыккач, Кызыл Мәйданнан ерακта түгел урнашкан Ленин музеенә таба атлыйлар.

Иптәш Сталинның инициативасы белән оештырылган бу музей дөньядагы иң бөек кешенең тормышын, көрәшен, омтылышын, кайгысын, шатлыгын тулысы белән синең күз алдыңа китереп бастыра.

Музейнең 21 зур залы бар. Аның һәрберсе Ильичнең гүзәл тормышы хакында сөйли.

Менә беренче зал.

Бу залда без даһинең балачагы белән танышабыз.

Ильич бала вактыннан ук тырыш, эш сөючән була. Ул барлык кешелек дөньясы тудырган белемнәрне яхшы итеп үзләштерергә омтыла, тырышып укый. Ул гимназиягә керә. Һәр фәннән бишле билгесе алып укый. Гимназияне мактау кәгазе һәм алтын медаль белән тәмамлый.

Казан университетында ул үзенең беренче революцион чыгышын ясый. Патша палачлары тарафыннан Александр Ильичнең үтерелүе яшь революционерга бик нык тәэсир итә. Абыйсының юлы ялгыш булуын ул халыкка аңлатырга һәм Маркс—Энгельснең әсәрләрен тагын да ныграк укырга керешә.

Заллар менә шул турыда сөйлиләр.

Менә инде Ильич профессиональ революционер. Революционер гына да түгел, юлбашчы. Патша шымчылары Ильичне һәр почмактан посып сагалыйлар. Аны ничек тә юк итәргә, революцияне юлбашчысыз калдырырга маташалар.

1900 нче елның 27 нче декабрендә Москва охранкасының начальнигы Зубатов:

„... Аларның җыелышларын басып, үзләрен кулга алсаң яхшы булыр иде. Ульянов һәм башкаларның тоткан урыннары ачык билгеле булганга күрә, бу башны революцион гәүдәдән тизрәк кисеп ташларга кирәк иде..."—дип язды.

Ильичне төрмәләргә утырталар, салкын якларга сөрәләр. Бөек кеше һәр җирдә үзенең фикердәшләрен таба, үзенең юлын халыкка өйрәтә. Әллә нинди салкын җирләрдә дә Ильич үз йөрәге өчен җылылык таба. Төрмәләрдә ул үзенең белемен тирәнәйтә, чөнки ул бер җиңүгә дә көрәшсез ирешеп булмаганын, ә белемсез көрәшеп булмаганны Марксның даһи әсәрләре аша бик яхшы аңлый. Төрмәдә вакытында икмәк йомшагыннан кара савыты ясап, кирәкле язуларын сөт белән китап юллары арасына язып, үзенең иректәге иптәшләре белән хәбәрләшә.

Илнең һәр почмагында ленинчеләр халыкны азатлыкка, якты тормышка чыгару өчен үзләренең эшләрен көн-төн дәвам иттерәләр.

Залларның берсендә, урта бер җиргә кызыклы бер макет урнаштырылган. Бу — иптәш Сталин тарафыннан оештырылган большевикларның Авлабардагы яшерен типографияләре макеты. Гади генә бер өй. Анардан ерακта түгел бер лапас тора. Аның эчендә кое. Яшерен типография эшчеләре шул кое чиләгенә утырып түбәнгә төшерә торган булганнар. Чиләк суга җиткәнчегә кадәр туктаган һәм эшчеләр ян-якка таба сузылган җир астындагы юл буйлап әлеге йорт астына эшләнгән типографиягә барганнар. Шул типографиядә большевиклар партиясенең ялкынлы прокламацияләре басылган. Бу типография ике ел буена уңышлы эшләп килгән. Полиция никадәр эзләсә дә, аны таба алмаган. Чираттагы бер тентү вакытында полицейскийлар шул йортка килеп кергәннәр. Йорт хуҗасы билгеле урындагы кнопканы басып бу куркынычлык турында типографиядәгеләргә хәбәр иткән, эшне туктатырга кушкан. Полицейскийлар шикләнеп бик нык эзләсәләр дә, берни таба алмаганнар. Бер нинди нәтиҗәсез чыгып китсәләр, араларыннан бер ерткычрагының, күзе әлеге лапаска төшкән. Һәм ул анда кергән. Гади коены күргәч тә әле бу ерткыч үзенең эзләнүен, иснәнүен һаман дәвам иттергән. Бер кәгаз кисәген яндырган да коега ташлаган, ә үзе янып торган кәгазнең түбәнгә төшүен күзәтеп торган. Кәгаз ни өчендер суга төшеп җитмәгән, ә һава агымы белән суырылып берякка таба кереп киткән. Менә шулай итеп бөтен сер ачылган...

Иптәш Бериянын кушуы буенча бу типография 1937 нче елны иске хәленә китерелгән.

Залларның берсе Ленин һәм Сталин арасындагы дуслык турында сөйли. Художник Моралов бу ике даһиның 1905 нче елны Таммерфорстагы беренче мәртәбә очрашуларын соклангыч матур итеп эшләгән. Ике бөек дусның көрәшүләрендә ягымлылык, бер-беренә мәңге бирелгәнлек күренеп тора.

Менә инде без алдынгы кешелекнең мәңгелек хыялы булган ирек таңының балкыган көннәренә—Октябрь штурмасына багышланган залда. Стеналар зур-зур рәсемнәр белән бизәлгәннәр, төрле документлар эленгән. Әнә Смольный. Аның биек-биек колонналары янында, эшчеләр, матрослар, красногвардеецлар арасында революциянең юлбашчылары Ленин һәм Сталин басып торалар. Алар капиталның соңгы калдыкларын шартлатырга бу корыч ташкынга юл өйрәтәләр.

Ленин—Халык Комиссарлары Советы председателе. Әнә шул яшел каләм сабы белән ул Совет властеның беренче декретларына кул куйган.

Халык дошманнары революциянең ялкынлы трибунын юк итәргә берничә мәртәбә маташып карадылар. Аларның бер җыланы—эсерка Каплан Ленингә агулы пуляләр белән атты. Әнә ул канлы браунинг, әнә ул агулы пуляләр. Алар хәзер пыяла шкафта яталар.

Әнә иптәш Ленинпең бархыт якалы пальтосы. Анда пуля тишкән эзләр күренеп торалар. Надежда Константиновна ул тишекләрне тупчып тегеп куйган.

Шул тарихи әйберләргә карап йөрәктә дошманга булган нәфрәт уты тагын да көчле булып яна башлый. Тамакка ниндидер төен килеп тыгыла, йодрыклар ихтиярсыз йомарланалар.

Хезмәт ияләре үзләренең юлбашчыларын гаҗәп бер сөю белән яраталар. Илебезнең ерак почмакларыннан, безнең илдән генә түгел, чит илләрдән аңа үзләренең кайнар сәламнәрен, үз куллары белән эшләгән бүләкләрен җибәрәләр.

Әнә стенада 70 яшьлек бер карчыкның бүләге эленеп тора. Ул кызыл бархытка эшче-крестьян элемтәсенең символы булган урак-чүкечне төшергән дә, аның астына үзенең сөйгән улының революция юлында корбан булганын әйтеп, „сиңа безнең атабыз улым истәлеге итеп чиктем" дип язган. Әнә Кытай хатын-кызлары җибәргән кызыл байрак, әнә Иран эшче хатын-кызларының бүләге.

Бер почмактагы пыяла рамкага алынган кечкенә бер кәгазьгә күз төшерәбез. 1919 нчы елда Меликинский өязеннән Иванов дигән бер крестьян эш белән Ленин янында, аның кабинетында була. Ленин кабинетының суык булуын күреп кайта һәм өязгә кайткач бу турыда сөйли. Өяз башкарма комитеты Ленингә бер вагон утын җибәрергә, кирәк булса бүлмәсенә тимер пич куярга дигән бу карарны чыгара. Менә бу кечкенә генә факт үзе генә дә халыкның юлбашчыны ничек яратуын һәм аның турында кайгыртуын бик көчле итеп сөйли.

Траур залына килеп керүгә синең һәр ягыңны кайгы чорнап ала. Күп сугышларны кичкән кызыл байракларга биредә кара бантлар тагылган. Биредә Ильичнең гипстан эшләнгән маскасы. Биредә Ильич табутына куелган веноклар. Алар Ленин үлеме аркасында кешелек дөньясының нинди зур югалтуга очравын, йөрәктән чыккан кайгылы сүзләрне төрле телләрдә сөйләп бирәләр.

Конференц залның экранында без тере Ленинне күрәбез. Аның ялкынлы речь сөйләүләре, тормышының кайбер эпизодлары мәңге онтылмаслык итеп пленкага төшерелгәннәр.

Менә ул чын кеше! Менә ул чын гомер! Юлбашчының тормышы безне батырлыкка өйрәтә, көрәшкә чакыра, Ватанны, халыкны аның кебек сөя белергә куша. Аның тормыш юлы барлык алдынгы кешелек өчен бөек үрнәк булып тора!

Менә инде музейнең зур ишекләре ябылалар.

Москваның шау-шулы урамына чыккач та әле син музейдән алган көчле тәэсирдән аерыла алмыйсың. Кремль сәгатьләренең көчле итеп сугуына син уянып китәсең һәм күзләреңне башняләрнең ахак йолдызларына, тарихи Кремльгә тегисең. Шул стеналар артында Ленинпең бөек эшен дәвам иттерүче кеше турында уйлый башлыйсың.

А. Алиш.

III-40 Москва.

Чит илләрдә

СКАНДИНАВИЯДӘ СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

ЛОНДОН, 22 апрель. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Тронгейм районында зур сугышлар башланырга тора. Норвегия гаскәрләре Стейнкьерда тупланганнар, анда алар Англия—Франция көчләре белән элемтә урнаштырганнар. Англиянең һәм Франциянең Норвегиядәге экспедицион гаскәрләренең саны өч дивизия күләмендә яки 50 мең кеше исәпләнә.

Германиянең парашютчылар частьләре норвегиялеләр кулындагы Домбос станциясен—Осло—Тронгейм тимер юлындагы узловой пунктны алырга берничә тапкыр омтылыш ясаганнар. Норвегиянең рәсми белдерүе, Германиянең бу районга төшкән 50 парашютчысының пленгә алынганлыгын раслый.

ЛОНДОН, 22 апрель. (ТАСС). Рейтер агентлыгы кичә Англиянең авиация министрлегенең түбәндәге рәсми белдерүен тапшырды: „Кичә төнлә белән һәм бүген иртә белән Англия авиациясе дошманның транспорт самолетларына һәм аэродромнарына һөҗүм итүне дәвам иттерде. Германиянең Ольборгдагы (Даниянең төньяк өлеше) авиабазасына уңышлы һөҗүм итү белән бергә, Англия авиациясе Германиянең Кристиансундтагы һәм Ставангердагы аэродромнарын бомбага тоткан. Англиянең барлык самолетлары да үз базаларына уңышлы кайтканнар“.

ЛОНДОН, 22 апрель. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, кичә Намсос районында Германия авиациясенең эше шактый көчәйгәнлеге сизелде. Германия самолетлары күп санда бомбалар ташлаганнар. Бомбага тоту нәтиҗәсендә шәһәргә шактый зур зиан килгән. Бомбардировка вактында Англиянең траулеры батырылган.

Бер үк вакытта, Стокһольмнан көньякта Германиянең 4.465 тонна авырлыктагы „Юрден Фритцен“ сәүдә пароходы батырылганлыгын хәбәр итәләр. Пароходның 30 кешелек командасы коткарылган.

ЛОНДОН, 22 апрель. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, авиация министрлеге кичә кич белән Англия самолетларының Ставангердагы аэродромны тагын бомбага тотканлыкларын белдергән. Аэродромда булган берничә самолет юк ителгән. Англиянең барлык бомбардировщиклары да үз базаларына уңышлы кайтканнар.

БЕРЛИН, 22 апрель. (ТАСС). Информация бюросының хәбәр итүенә караганда, Германиянең Норвегиядә хәрәкәт итүче гаскәрләре тарафыннан алынган сугыш кирәк-яраклары саны көннән-көн арта. Портларда ясалган тентүләр вактында күп санда кораллар һәм материаллар табылган.

Аерым алганда, 20 нче апрельдә, Бергендагы складларда Англиягә озату өчен билгеләнгән 380 мең пар итек табылган.

БЕРЛИН, 22 апрель. (ТАСС). Германия армиясенең верховный командованиесе түбәндәге сводканы игълан итте: „Дошманның хәрби диңгез көчләре кичә Нарвикка яңадан ут ачканнар. Тронгейм районында кичә безнең тарафтан әһәмиятле пунктлар алынды. Германиянең Осло һәм Кристиансунд районнарына урнашкан гаскәрләре белән Ставангер аркылы элемтә урнаштырылды. Германиянең Ослодан төньякта һәм төньяк-көнбатыш юнәлештә хәрәкәт итә торган гаскәрләре Норвегия частьләре белән сугыштылар һәм аларны чигендерделәр. Бу вакытта Гьевик һәм Лиллехаммер алынды. Дошман авыр югалтуларга дучар ителде.

Германия истребительләренең кечкенә бер берләшмәсе Намсос һәм Ондалснес тирәләренә англичаннарның десант төшерергә маташуларына уңышлы рәвештә каршылык күрсәтте. Алар дошман тарафыннан алынган вокзалларны җимерделәр. Англиянең бер эсминецы һәм ике сәүдә пароходы зарарланды һәм батырылды. Хамара районында безнең авиация дошманнар кулындагы тимер юл линияләрен җимерде. Немецләр Осло гарнизоны арсеналын кулга төшерделәр, анда шактый күләмдә сугыш кирәк-яраклары запасы бар иде. Скагерракта һәм Каттегатта дошманның 2 су асты көймәсе юк ителде. Англия самолетлары Ольборгдагы аэродромга һөҗүм иттеләр, ләкин берниндә зарар китерә алмадылар. Англиянең 3 самолеты бәреп төшерелде. Болардан тыш төнлә белән Германия ярлары өстендә бер самолет бәреп төшерелде“.

БЕРЛИН, 22 апрель. (ТАСС). „Цвельфурблат“ газетасы хәбәр итә: Норвегия ярлары янындагы сугышларның 12 көне эчендә Англия 4 линкорын, 2 линейный крейсерын, 1 авианосецын, 4 авыр крейсерын, 10 җиңел крейсерын, 12 эсминецын, 13 су асты көймәсен, 29 самолетын һәм 15 транспорт судноларын югалткан. Боларның 60 ы бөтенләй юк ителгән. Калганнары авыр һәм җиңел рәвештә зарарланганнар.

Англиядә Беренче Май бәйрәменә хәзерлек

ЛОНДОН, 22 апрель. Англия эшчеләр сыйныфы быел Беренче Май бәйрәменә яңа империалистик сугыш шартларында, илдә реакциянең чиктән тыш көчәйгән һәм хезмәт ияләренең кин массасының тормыш дәрәҗәләренә капиталистларның рәхимсез һөҗүме шартларында хәзерләнә. Англия реакционерларының һәм аларның лейбористлар лагерендагы лакейларының Англия компартиясен тыеп тору итүләре көннән-көн кабахәтрәк булып бара. Коммунистлар партиясендә член булып торучылары өчен генә дә полициянең коммунистларны эзәрлекләү вакыйгалары ешайды. Бер күренекле либерал ачыктан-ачык: „Әгәр дә хөкүмәт компартияне тыя икән, мин каршылык күрсәтмәячәкмен“ дип белдерде. Моннан берничә көн элек парламент членнарыннан—консерваторлардан 70 кеше коммунистларга каршы һәм Англиянең „илен рухын җимерергә омтылучы“ башка граждан оешмаларына каршы чаралар күрергә хөкүмәттән таләп итте.

Сугыш обстановкасы сылтавы белән хөкүмәт Лондонда демонстрацияләр ясауны тыйды һәм шулай итеп Лондон эшчеләре Лондон урамнарыннан үтү мөмкинлегеннән мәхрүм ителделәр.

Шушы шартларда компартия Беренче Май бәйрәмен үткәрү буенча эшне кин җәелдерде. Беренче Май җыелышларын һәм митингларын үткәрү максатында лейбористлар партиясе оешмалары белән бергә коммунистлар, җыелышлар, митинглар һәм демонстрацияләр тыелмаган провинциаль шәһәрләрдә шулай ук Беренче Май көнне демонстрацияләр үткәрергә хәзерләнәләр. Бу көнне Лондондагы Гайд паркта массовый митинг булачак. Кич белән ябык биналарда җыелышлар оештырылырга билгеләнә. Болардан тыш, Лондонда туры заводларда һәм фабрикаларда күп кенә митинглар оештырырга уйланыла.

Глазгоның коммунистик оешмасы шәһәрнең барлык эшчеләр оешмаларына Беренче Май демонстрациясендә һәм митингта катнашуга чакырып мөрәҗәгать итте, бу демонстрациядә һәм митингта парламент члены Галлахер һәм компартия җитәкчелегенең бер члены Кэмпбелл речь сөйләячәкләр.

Манчестерда һәм Ливерпульда предприятиеләрдә массовый митинглар булачак. Йорк графствосының күп кенә шәһәрләрендә Беренче Май демонстрацияләре һәм предприятиеләрдә митинглар булачак. Коммунистик партиянең Бристоль оешмасы предприятиеләрнең капкалары янында митинглар үткәрергә һәм демонстрацияләр оештырырга уйлый. Брайтонда хатын-кызлар җыелышы сугышны туктатуны, квартира хакын киметүне һәм балаларны укыту өчен нормаль шартлар тудыруны таләп итеп Беренче Май көнне демонстрация үткәрәчәк.

Беренче Май бәйрәменә хәзерлек Англиянең ил кечкенә генә шәһәрләрендә дә һәм местичколарында да алып барыла. Беренче Май бәйрәменә хәзерлек уңае белән лейбористлар партиясе җитәкчелеге үзенең урыннардагы оешмаларына сугышка каршы булган лозунглар һәм таләпләр белән чыгуны бик нык тыйды.

КЫТАЙНЫҢ ТӨНЬЯК-КӨНБАТЫШ ФРОНТЫ КОМАНДУЮЩИЕ ЧЖЕНЬ ЦЗЯН ИНТЕРВЬЮСЫ

ЧУНЦИН, 22 апрель. (ТАСС). Төньяк-көнбатыш фронтның командующие генерал Чжень Цзян матбугат вәкилләренә интервью бирде, ул болай диде:

„Кытай Япониягә каршы булган сугышта дошманның җанлы көчләрен юк итү һәм аның ресурсларын какшату принцибыннан чыгып эш итә.

Сугыш башланганнан бирле без зур уңышларга ирештек. Илебез япон сугыш чукмарларына удар ясарга хәзерләнә. Илебездә патриотизм рухы үсә. Кытай армиясенең хәрби күнегүе һәм мораль хәле көннән-көн күтәрелә.

Кытайның озакка сузылган сугыш алып бару өчен уңайлы шартлары бар. Ул авыл хуҗалыгы иле. Без чимал һәм азык белән тулысынча тәэмин ителгән һәм безнең чиксез күп кешеләр ресурсларыбыз бар. Хәзер Кытайның резервта хәрби өйрәнү үткән 70 тән артык дивизиясе бар. Дөрес, ягулык белән тәэмин ителүдә бездә житешсезлекләр сизелә, ләкин бу Японияга каршы сугыш алып баруга комачауламый.

Кытай армияләренә каршы японнарның һөҗүмнәре бер-бер артлы уңышсызлыкка дучар була. Япония сугыштан чыгу мөмкинлеге булмаганлыктан, политик интригаларны көчәйтүен дәвам иттерә. Үзәк курчак „хөкүмәте“ төзелү японнарның көчсезлеген тагын бер тапкыр раслый. Ван Цзин-вей һәм аның иярченнәре кытай халкы алдында хөрмәт тә, ышаныч та казана алмыйлар“.

Реченең ахрында Чжень Цзян болай диде: „Башка фронтларда кытай гаскәрләренең уңышлы хәрәкәт итүләре японнарның озакка сузылган сугыш алып бара алмауларын тагын бер тапкыр күрсәттеләр. Без, тәмам җиңүебезгә ышанабыз һәм корал белән каршылык күрсәтүебезне ахрынача дәвам иттерербез“.

Питрәчтәге балалар бакчасында тәрбияләнүче бер төркем балалар прогулкадан кайталар. Г. Широков фотосы (ТАСС фото-клишесе).

В. И. ЛЕНИННЕҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Ленин булган урыннарга экскурсия

Су юллары ачылу белән Казанга чит шәһәрләрдән экскурсияләр оештыру турында заявкалар алына башлады. 3 нче майда Москвадан Казанга пароход белән 150 кешелек экскурсиячеләр группасы килә. Алар Казанда 2 көн булачаклар һәм тарихи памятникларны, Ленин булган урыннарны караячаклар.

Экскурсиягә килүчеләр пролетариатның бөек юлбашчысы Ленин исеме белән бәйләнгән урыннар белән аеруча кызыксыналар. Татарстанның Туризм һәм Экскурсияләр Идарәсе моны искә алып, Казанда Ленин булган урыннарга экскурсияләр ясау өчен 40 мең данә путевка бастырып чыгарды.

Казан Дәүләт университетында

В. И. Ленин исемендәге Казан Дәүләт университетының студентлары һәм укытучылары бөек юлбашчының туына 70 ел тулу көнен зур күтәренкелек белән каршыладылар. В. И. Ленинның тормышы һәм иҗады турында беседалар һәм докладлар үткәрелде. Университетның үзендә һәм аның янындагы фәнни көтепханәдә В. И. Ленинга багышланган гаять бай күргәзмәләр оештырылды.

21 нче апрельдә даһи юлбашчының Казандагы тормышы һәм революцион эше турында марксизм-ленинизм кабинетыннан радиотапшыру үткәрелде.

Казан Дәүләт университетының агитаторлары җирле Советларга сайлаулар вактында эшләгән участкыларда бүген һәм иртәгә В. И. Ленин турында беседалар үткәрәләр.

Биектау районында

Биектау районының ОГПУ исемендәге колхозында В. И. Ленинның туына 70 ел тулу көненә багышлап, колхозчыларның һәм авыл интеллигенциясенең гомуми җыелышы булды. Җыелышта катнашучылар В. И. Ленинның тормышы һәм эше турында агитатор иптәш Морозов докладын зур игтибар белән тыңладылар.

Мехкомбинатта

22 нче апрельдә көндезге аш вактында Казан мех предприятиеләренең барлык цехларында һәм сменаларында, шулай ук Яңа бистәдә элек сайлау участкылары булган урыннарда уннарча агитаторлар, В. И. Ленинның туына 70 ел тулу көненә багышлап, беседалар һәм кычкырып укулар үткәрделәр. Өченче мех фабрикасының агитаторы яшь инженер иптәш Куликовский Ленинның тормышы һәм революцион эше турында скорняктегү һәм яка цехларының барлык сменаларында беседалар үткәрде. Ул эшчеләргә һәм эшче хатын-кызларга, кешенең кеше тарафыннан эксплоатацияләнүен бетергән, культурасызлыкны һәм караңгылыкны бетергән илебездә бөек юлбашчының васиятләре ничек үтәлә икәнлеге турында сөйләде.

Казан мехкомбинатының капиталь төзелеш бүлегенең агитколлективы элекке сайлау участкысында һәм тулай торакта 19 нчы апрельдән бирле йорт хозяйкалары арасында көн саен беседалар үткәрә. Агитатор иптәш Олецкая йорт хозяйкалары арасында инде 3 беседа үткәрде.

Мех промышленносте эшчеләренең көтепханәсе, техника әдәбияты көтепханәсе һәм парткабинет бөек В. И. Ленинның тормыш юлын күрсәтә торган күргәзмәләр-витриналар оештырдылар.

Баулы районында

В. И. Ленинның туына 70 ел тулу көненә багышлап Баулы районының 27 колхозында 22 нче апрельдә җыелышлар булды.

„Берлек“ колхозында җыелышта колхозчы иптәш Гәрәев речь сөйләде. Ул болай диде:

— Халыкларның бөек юлбашчысы В. И. Ленинның туына 70 ел тулу көненең данлыклы еллыгын истә калдырып, Ленин һәм Сталин өйрәткәнчә колхозда тагын да яхшырак эшләрбез. Колхоз производствосының стахановчылары сафларын арттырырбыз.

Ильичнең туына 70 ел тулу көненә багышлап ВКП(б) райкомы парткабинетында күргәзмә ачылды. Күргәзмәне караучы колхозчылар, эшчеләр һәм интеллигентлар Ленинның тормышы һәм эше турында күп кенә сораулар бирәләр.

БЕРЕНЧЕ МАЙГА ХӘЗЕРЛЕК

Массовый җырлар өйрәнәләр

Бөек бәйрәмгә хәзерлек уңае белән „Спартак“ комбинатының ФЗӨ мәктәбе укучылары яңа чыккан массовый җырларны өйрәнәләр. Һәр көнне маршировкалар үтәләр.

Классларда 1 нче Май турында беседалар алып барыла. Укучылардан 35 кеше Ворошиловча атучы значогына һәм 25 кеше ПВХО значогына нормалар тапшыруга хәзерләнәләр.

Мәктәпнең рус һәм татар драма түгәрәкләре бәйрәм кичәсенә махсус программа хәзерлиләр. Алар Май көннәрендә комбинат эшчеләре өчен концерт бирәчәкләр.

Беренче Майны үткәрү комиссиясе мәктәпне бизәү өчен эскизлар хәзерли.

Бәйрәм кичәләре

2 нче номерлы урта мәктәп (Сталин районы) бинасы „Бәхетле балалык өчен иптәш Сталинга рәхмәт“ дигән темада бизәлә. Укучылар 1 нче Май демонстрациясенә алып чыгу өчен төрле төстәге кәгазьләрдән җир шарының зур макетын ясыйлар, лозунг, плакатлар язалар.

31 нче апрельдә югары класс укучыларының бәйрәм кичәсе үткәреләчәк. 1 нче һәм 2 нче май көннәрендә кече яштәге укучы балалар өчен иртәлекләр үткәрелә.

Бәйрәм көннәрендә мәктәп үз шефлыгындагы „Красный путь“ заводына барып, эшчеләр өчен концерт бирәчәк.

Бәйрәмгә чәчәкләр

Горзеленстрой 1 нче Майга 4.000 банкага якын чәчәкле гөл һәм 3.000 төп чамасы декоратив үсемлекләр хәзерләп чыгара.

Якын көннәрдә Ленин исемендәге завод территориясен яшелләндерү башланачак. Анда 13.000 төп төрле агачлар утыртылачак. Шулай ук Серго Орджоникидзе заводы, Кинопленка һәм башка предприятиеләр дә үзләренең территорияләрен яшелләндерәчәкләр.

БЕЛДЕРҮ

26 нчы апрель, кич 6 сәгатьтә Шәһәр Советының утырышлар залында (35 нче бүлмә) „1940 нчы елда шәһәр төзеклеге“ дигән темада лекция үткәрелә. Лектор—Горкомхозның баш инженеры иптәш Казанкин.

Шәһәр Советының һәм район советларының депутатлары чакырылалар.

27 нче апрельдә, кич 6 сәгатьтә „Кызыл Татарстан“ газетасы редакциясендә хезмәт ияләре депутатларының Казан Шәһәр Советы һәм шәһәрдәге район советлары председательләренең һәм аларның урынбасарларының, шәһәр һәм район советларының даими комиссияләре председательләренең киңәшмәсе була. Көн тәртибе: эш тәҗрибәләре белән уртаклашу. Шәһәр һәм район советлары председательләренең (яки аларның урынбасарларының), шулай ук даими комиссияләр председательләренең киңәшмәгә күрсәткән вакытта килүләре сорала.

Редактор урынбасары И. ҮЗБЕКОВ.
Зам. редактора И. УЗБЕКОВ.

Клублар, уку йортлары, фабрикалар, заводлар, учреждениеләр һәм хәрби частьләр игтибарына!

БЕРЕНЧЕ МАЙ ТАНТАНАЛАРЫНА КАРАТА

Биналарны, җыелыш залларын, колонналарны һәм стена газеталарын бизәү өчен,

КОГИЗ МАГАЗИННАРЫНДА

юлбашчыларның портретлары һәм бюстлары, стэндлар, плакатлар, лозунглар, байраклар, СССР һәм РСФСР герблары һәм открыткалар сатыла.

Магазиннарның адреслары: № 1—Бауман урамы, Матбугат йорты, телефон—6—43. № 2—Киров урамы, 72; телефон 30—07. № 3—Пионер урамы, 6-2; телефон 3—58. № 8—Гладилов урамы, 22; телефон 34—51. КОГИЗ. 662—2—1

Главспецстройның 1940 нчы ел, 29 нчы мартта чыгарган 130 нчы номерлы приказы һәм „Элеваторстрой“ трестының 1940 нчы ел 1 нчы апрельдә чыгарган 40 нчы номерлы приказы нигезендә,

„Элеваторстрой“ның Казан Өлкә конторасы

1940 нчы ел, 1 нче майдан

бетерелә

„Элеваторстрой“ Казан Өлкә конторасының барлык активлары һәм пассивлары „Элеваторстрой“ трестына күчерелә.

„Элеваторстрой“ Казан Өлкә конторасына карата дәгъвалары булган барлык оешмалар һәм частный кешеләр ул турыда 1940 нчы ел 1 нче майга кадәр белдерергә тиешләр.

Күрсәтелгән сроктан соң дәгъвалар алынмаячак. 665—1

СССР Госпланы Халык Хуҗалыгы Учеты Үзәк Идарәсенең

УКЫТУ КОМБИНАТЫ

производстводан аерып укытып, киләчәктә Ленин районы территориясендәге заводта эшләү өчен Казанда

ХИСАПЧЫЛАР ХӘЗЕРЛӘҮ КУРСЛАРЫ АЧА

Курсларда укучыларга, аларның академик өлгерешләренә карап, айга 150 сумнан 225 сумга кадәр күләмендә стипендия бирелә. Уку срогы алты ай.

Курсларга 17 дән 25 кә кадәр яштәге, кимендә 7 класс күләмендә белемле һәм Казанда даими тору урны булган кешеләр алыналар.

Гаризалар Укыту комбинаты канцеляриясендә һәр көн иртән 9 сәгатьтән көндез 3 кә кадәр алына. Казан, Чернышевский урамы 11. 621—1

„КАЗИНТОРГ“ АРТЕЛЕНЕҢ

ӘЙБЕР САТЫП АЛУ ПУНКТЛАРЫ

ГРАЖДАННАРДАН ҺӘМ ОЕШМАЛАРДАН

ҺӘР ТӨРЛЕ ӘЙБЕРЛӘР:

тегелгән киемнәр, аяк киемнәре, баш киемнәре, паласлар, трикотаж әйберләр, стена сәгатьләре, күзгеләр, каты һәм йомшак мебельләр, көн-көнеш әйберләр, пролеткалар, йөк арбалары һәм башка әйберләр

сатып алалар

Әйбер сатып алу пунктларының адреслары: пункт № 27—Свердлов урамы, 2. Пункт № 28—Бауман урамы, 64. Пункт № 32—Париж Коммунасы урамы, 13. Телефоннар: 18—33 һәм 1—39. Әйберләр сатып алучы агентлар сорату буенча өйләргә җибәреләләр. 654—2—1 „Казинторг“ артеле идарәсе.

РСФСР Наркомлегпромының 1940 нчы ел, 31 нче мартта чыгарган 123 нче номерлы приказы нигезендә,

КАЗАНДАГЫ КҮН ТЕХНИКУМЫ БЕЛӘН КИЕЗ ИТЕК-ФЕТР ТЕХНИКУМЫ БЕРГӘ КУШЫЛА

һәм элекке ике техникумны берләштергән яңа техникум

„РСФСР НАРКОМЛЕГПРОМЫ КИЕЗ БАСУ ҺӘМ КҮН ПРОМЫШЛЕННОСТЕНЫҢ КАЗАН ТЕХНОЛОГИЯ ТЕХНИКУМЫ“ ДИП ИСЕМЛӘНДЕ

Элекке һәр ике техникумга карата булган барлык дәгъвалар 1940 нчы ел 28 нче апрельгә кадәр алына. 649—1

„Росглавхлеб“ трестының 1940 нчы ел, 4 нче апрельдә чыгарган 57 нче номерлы приказы нигезендә, „Росглавхлеб“ Татарстан трестының

агач материаллары һәм утын хәзерләү базасы,

хуҗалык исәбендәге аерым оешма булуы ягыннан,

шушы ел, 1 нче апрельдән

бетерелде

Барлык оешмалардан расчетлар буенча булган дәгъвалар шушы ел, 1 нче майга кадәр алына.

Агач материаллары һәм утын хәзерләү базасының барлык функцияләре һәм договорлар буенча булган барлык йөкләмәләре „Росглавхлеб“ Татарстан трестының Агач материаллары хәзерләү һәм сату конторасына күчерелә.

Дәүләт Банкасы Татарстан Республика конторасында, Агач материаллары хәзерләү һәм сату конторасының расчетлар счеты № 55107. 663—3—1

ЭНЕРГОСБЫТ

БЕЛДЕРӘ:

1 нче Май тантаналарына карата ясалган

ИЛЛЮМИНАЦИЯЛӘР

Энергосбыт тарафыннан кабул ителгәннән соң һәм аның рөхсәте белән генә электр челтәренә

ТОТАШТЫРЫЛА АЛА

Иллюминациянең көче нинди булуын күрсәтеп, шушы ел, 28 нче апрельгә кадәр Энергосбытка заявкалар бирергә. 676—1

Казгорпищеторг тарафыннан, Стройконтора директоры Федор Иванович Власов исеменә бирелгән 1—1112 нче номерлы ышаныч кәгазен, югалган булу сәбәпле, гамәлдән чыккан дип санарга. 658—1

Авиация промышленносте эшчеләре союзы Үзәк Комитеты ял йортлары һәм санаторийлар идарәсенең

ЗӘҢГӘР КҮЛ ЯЛ ЙОРТЫ

1940 нчы елгы сезонда ял итүчеләр үткәрү буенча

ДОГОВОРЛАР ТӨЗИ БАШЛАДЫ

Шартлары турында белешү өчен адрес: ТАССР Юдино районы, Кадышево почта бүлеге. 659—3—1

„Зеленодольский рабочий“ газетасы редакциясенең югалган түгәрәк печатен гамәлдән чыккан дип санарга. 675—1

КИРӘК:

Скорняк-Тегү фабрикасына, МАШИНАДА ТЫШКЫ КИЕМНӘР ТЕГҮЧЕ ХАТЫН-КЫЗЛАР, СКОРНЯК-НАБОРЩИКЛАР һәм ЮГАРЫ КВАЛИФИКАЦИЯЛЕ ИТЕКЧЕЛӘР. Казан, Тукай урамы, 14/15, фабриканың кадрлар бүлеге. 677—5—1

Казан Нефтебазасына даими эшкә ЙӨК ТАШУЧЫЛАР, НЕФТЬ САЛУ БУЕНЧА ЭШЛӘҮЧЕЛӘР, БОНДАРЬЛАР, БОНДАРЬЛЫК БУЕНЧА ЯРДӘМЧЕ ЭШЧЕЛӘР, ТИМЕРЧЕ, ЧҮКЕЧ СУГУЧЫ, КОЧЕГАРЛАР, АВТОТРАНСПОРТ ӨЧЕН ГРУЗЧИКЛАР һәм резервуарларның клепкаларын формалаштыру эшләре буенча КОТЕЛЬЩИКЛАР. Хезмәт хакы эш башыннан түләнә. Эшчеләр өчен тулай торак бар. Казан, Яңа бистә, Зур Ямашев урамы, 2, Нефтебаза конторасы. 651—2—1

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ

Бүген яңа программа буенча

ЗУР ЦИРК УЕНЫ

ФРАНЦУЗЧА КӨРӘШ

ЯРЫШЫ ДӘВАМ ИТӘ

ҺӘР КӨН 3 ПАР КӨРӘШӘ

Бүген зур программада

КӨНДЕЗГЕ ЦИРК УЕНЫ

Уеннар: көндез 12 дә, кич 8 дә башлана. Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 1 гә һәм кич 5 тән 11 гә кадәр ачык.

Галиәсгар Камал исемендәге

Татар Дәүләт Академия театры

25, 26 һәм 27 нче апрельдә, шулай ук 30 нчы апрельдә көндез һәм кич премьера

ХУҖА НАСРЕТДИН

Иртәгә „2“ штампы сугылган билетлар белән кертелә.

Спектакль кич 8 сәгатьтә башлана. ТДАТ.

Киров районы

КУЛЬТУРА САРАЕНДА

Бүген, 24 нче апрельдә

МАСКАРАД

Кич 8 дә башлана.

Татстройтрестның җитештерү конторасында һәр төрле

ТӨЗҮ МАТЕРИАЛЛАРЫ һәм САНТЕХНИКА МАТЕРИАЛЛАРЫ

— САТЫЛА —

655—1

Казан Шәһәр Ветеринария бүлеге паспорт пунктының урланган түгәрәк печатен гамәлдән чыккан дип санарга. 596—1

Казмехкомбинатның 2 нче мех фабрикасына даими эшкә ХИСАПЧЫЛАР, РАСЧЕТЧЫ БУХГАЛТЕРЛАР, ТЕПЛОТЕХНИКЛАР, ТОКАРЬЛАР, 5—6 нчы РАЗРЯД СЛЕСАРЬЛАР һәм ЦЕХЛАР ӨЧЕН ӨЛКӘН БУХГАЛТЕРЛАР кирәк. Кече Ямашев урамы, 86 (6 нчы маршрут трамвае белән барыла). 633—1

ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ТЕАТРЫ

Бүген, 24 нче апрельдә

Татар Дәүләт Академия театры бинасында көндез

ФАЙДАСЫЗГА САКЛАНУ

Кич—**ИРЕК**

Иртәгә Зур театр бинасында

ФАУСТ

Коллектив рәвештә килү өчен 29—04 телефоны буенча заявкалар алына.

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ

Бүген, 24 нче апрельдә көндез

КУРКЫНЫЧЛЫ СУД

Кич—**МЕТЕЛЬ**

26 нчы апрельдә

БАКЧАЛАР ЧӘЧӘК АТА

Билетлар көндез 11 сәгать 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 7 сәгать 30 минутка кадәр кассада сатыла.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО“ 10, 12, 2, 4, 5-30, 7, 8-30, 10 да.	АРИНКА
„УНИОН“ 12, 2, 4, 6, 8, һәм 10 да.	МОРЯКЛАР
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ“ 6, 8, 10 да.	ЛЕНИН ОКТЯБРЬДӘ
„ЧАТКЫ“ 6, 8, 9-30 да.	ЛЕНИН 1918 нче елда
„ПИОНЕР“ 11, 1, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	ИНЖЕНЕР КОЧИННЫҢ ЯЛГЫШУЫ. Көндез 1 сәгатьтә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс.
„Колхозник“ 6, 8 һәм 10 да.	ВЫБОРГ ЯГЫ
„РОТ-ФРОНТ“ 6, 8, 10 да.	БӨЕК ТАҢ
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7 һәм 9 да.	ИСТРЕБИТЕЛЬЛӘР

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 1399. ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА, ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ №1594.